**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
**ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ**
***Гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы***

**З.Н. КИРИЛЛОВА**

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН СИНТАКСИС ҺӘМ ПУНКТУАЦИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ

Югары уку йортлары өчен
укыту кулланмасы

**Казан – 2020**

**УДК 81'367: 81'374.3**

**ББК 81.2Тат-2**

*КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Гыйльми советының Укыту-методик комиссиясе карары нигезендә басыла (беркетмә № 6, 2020 елның 16 марты).*

**Рецензентлар:**
филолология фәннәре докторы,
Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре
**Л.Х. Мөхәммәтҗанова;**
педагогика фәннәре кандидаты,
КФУның гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты
**К.С. Фәтхуллова**

**Кириллова З.Н.**
**Татар теленнән синтаксис һәм пунктуация терминнары сүзлеге. Югары уку йортлары өчен укыту кулланмасы**. – Казан: Казан ун-ты, 2020. – 60 б.

Кулланма югары уку йортларында белем алучы студентларның татар теле синтаксисы һәм пунктуациясеннән белемнәрен ныгыту максатына юнәлдерелгән. Сүзлектә терминнар хакында кыскача мәгълүмат бирелә, матур әдәбият әсәреннән яки сөйләм теленнән алынган мисал китерелә. Кулланма урта һәм югары уку йорты студентларына, магистр һәм аспирантларга, укытучыларга тәкъдим ителә. Ул шулай ук мәктәп укучылары, урта һөнәри белем бирү уку йортлары студентлары һәм, гомумән, татар теле белән кызыксынучылар өчен файдалы булыр.

**© Кириллова З.Н., 2020**

**© Казанский университет, 2020**

## ЭЧТӘЛЕК


Кереш........................................................................................................ 4
Татар алфавиты........................................................................................ 4
Татар теленнән синтаксис һәм пунктуация терминнары сүзлеге…................. 5
А.............................................................................................................. 5
Б.............................................................................................................. 10
В.............................................................................................................. 11
Г.............................................................................................................. 12
Д.............................................................................................................. 14
Җ.............................................................................................................. 14
З.............................................................................................................. 16
И.............................................................................................................. 16
К.............................................................................................................. 25
М.............................................................................................................. 31
Н.............................................................................................................. 32
О.............................................................................................................. 33
Ө.............................................................................................................. 33
П.............................................................................................................. 34
Р.............................................................................................................. 35
С.............................................................................................................. 37
Т.............................................................................................................. 42
У.............................................................................................................. 47
Ү.............................................................................................................. 48
Ф.............................................................................................................. 49
Х.............................................................................................................. 49
Ц.............................................................................................................. 51
Ч.............................................................................................................. 52
Ш.............................................................................................................. 52
Э.............................................................................................................. 52
Ю.............................................................................................................. 53
Әдәбият.................................................................................................... 54
Сүзлекләр.................................................................................................. 56
Интернет ресурслары................................................................................ 59

# КЕРЕШ

Сүзлектә татар тел белеменең синтаксис һәм пунктуация тармакларына караган терминнар тупланды. Ул сөйләм төзелешенә һәм тыныш билгеләрен кую кагыйдәләренә кагылышлы терминология буенча күзаллама тудырырга ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

Кулланмада терминнар алфавит тәртибендә тәкъдим ителде. Һәр терминга кыскача аңлатма бирелде, алынма сүзләрнең кайсы тел термины икәнлеге күрсәтелде. Лингвистик күренешләр матур әдәбияттан, сөйләм теленнән тупланган мисаллар белән дәлилләнеп барылды. Синоним терминнар булган очракта, кулланылыш даирәсе киңрәк булган вариантка аңлатма бирелде, ә башкалары сылтамалар белән күрсәтелде.

Укыту кулланмасы Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында белем алучы бакалавр, магистрант һәм аспирантларны күздә тотып төзелде, шул ук вакытта мәктәп укучылары, төрле уку йортларында эшләүче укытучылар һәм, гомумән, татар теле белән кызыксынучылар өчен дә файдалы булыр дип ышанабыз.

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| **А** | **И** | **Р** | **Ш** |
| **Ә** | **Й** | **С** | **Щ** |
| **Б** | **К** | **Т** | **Ъ** |
| **В** | **Л** | **У** | **Ы** |
| **Г** | **М** | **Ү** | **Ь** |
| **Д** | **Н** | **Ф** | **Э** |
| **Е** | **Ң** | **Х** | **Ю** |
| **Ж** | **О** | **Һ** | **Я** |
| **Җ** | **Ө** | **Ц** | |
| **З** | **П** | **Ч** | |

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН СИНТАКСИС ҺӘМ ПУНКТУАЦИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ

## А

**АБЗАЦ** (алм. *absatz*) – 1. Язма текстның яки аның аерым өлешенең эчкәрәк кертеп башланган беренче юлы. *Кара*: **Кызыл юл.** 2. Текстның ике кызыл юл арасындагы өлеше.

**АВТОР СӨЙЛӘМЕ** – чит сөйләмле текстта язучы яки сөйләүченең үз сүзләре. Мәсәлән, *«Эх, – дип кычкырып җибәрдем мин, бөтен Кабан буен яңгыратып, – дөнья матур бит!..»* (Ф.Шәфигуллин)

**АГЕНС** (лат. *agens (agentis)* – катнашучы) – җөмләдә тасвирланган ситуациядә катнашучының семантик роле. А. термины белән ситуациядә катнашучы, аны контрольдә тотучы, этәргеч бирүче яки процессны турыдан-туры башкаручы затны билгелиләр. А. гадәттә ия белән бирелә *(Илдар мәктәпкә бара)*, шулай ук кыек тәмамлык белән дә белдерелергә мөмкин *(Илдардан яздыру, Илдар аша әйттерү).*

**АДРЕСАНТ** (алм. *adressant* < фр.) – сөйләүче яки текстны язучы зат, хәбәрне җибәрүче.

**АДРЕСАТ** (алм. *adressat* < фр.) – 1. Сөйләм яки текст юнәлдерелгән зат, хәбәрне алучы. *Чаг.*: **Адресант**. 2. Предикат белән белдерелгән эш-хәрәкәт юнәлдерелгән актантның семантик рольләреннән берсе. Татар телендә морфологик яктан юнәлеш килешендәге сүз белән белдерелә. Мәсәлән, *әтигә бүләк итү, абыйга хат җибәрү*.

**АЕРГЫЧ** – җөмләнең исем яки исемләшкән сүз төркемнәре белән белдерелгән кисәген ачыклап, аның билгесен (сыйфатын, санын һ.б.) белдерүче иярчен кисәк. Аергыч мөстәкыйль сүз төркемнәре һәм хәбәрлек сүзләр белән белдерелә ала. Мәсәлән, *матур көн, егерме кеше, язасы хат, татарча спектакль, минем дәфтәрем, Галиянең дусты, юк-бар эш, укылган китап.*

**АЕРЫЛМЫШ** – аергычны ияртеп килгән сүз. Исем яки исемләшкән сүз төркемнәре белән белдерелә. Мәсәлән, *кояшлы яңгыр, ике толым, кечкенә килүчеләр.*

**АЕРЫМЛАНУ** – җөмләдә кайбер иярчен кисәкләрне интонацион, мәгънәви һәм формаль (пунктуацион) яктан аерып әйтү яки язу. Андый кисәкләр җөмләнең аерымланган кисәкләре дип атала. Татар телендә аергыч, тәмамлык, аныклагыч һәм хәлләр аерымланырга мөмкин. Аергыч – үзе буйсынган сүздән артта килгән очракта, тәмамлык, моннан тыш, интонацион яктан җөмлә эчендә калганда гына аерымлана. Мәсәлән, *Яз килде, дулкынлы, ялкынлы* (М.Җәлил). *Ул бик яхшы поэма язган, мәхәббәт турында* (Ш.Усманов). Аныклагычлар, аныкланмыш белән ярашкан очракта һәм аныклаучы теркәгечләр белән килгәндә, төрле тыныш билгеләре белән аерып куелалар. Мәсәлән, *Апрельнең башларында, җомга көннәрнең берендә, ул Осланга махсус дача карарга чыкты...* (К.Тинчурин) Хәлләр аерымлану өчен, ике төп шарт кирәк: хәл кисәкнең фигыль белән белдерелүе, ягъни ярымхәбәрлеккә ия булу; үзе ияргән сүздән ераклашкан булуы. Мәсәлән, *Минем җавапны алуга, ул килеп җиткән. Вафин, йокысыннан сискәнеп уянган кешедәй, җырга колак салды* (Ф.Хөсни). Урын хәлләре бервакытта да аерымланмый. Мәсәлән, *Тау башына салынгандыр безнең авыл* (Г.Тукай).

**АКТАНТ** (лат. *ago* – хәрәкәткә китерәм, хәрәкәтләнәм) – җөмләнең фигыль белән бирелгән процесста катнашучы затны яки предметны белдерүче кисәге. Бу төшенчәне беренче булып француз галиме Л.Теньер кертә һәм өч

А.ны аера: беренче (ия), икенче (туры тәмамлык яки пассив фигыльнең агенсы) һәм өченче (кыек тәмамлык). Синтаксисның семантик теориясендә А.ларны икегә бүләләр: семантик (реаль) А.лар – ситуация элементларын чагылдыручы (субъект, объект, адресат һ.б.) һәм синтаксик А.лар – җөмлә кисәкләре (ия, тәмамлык һ.б.).

**АКТУАЛЬ КИСӘКЛӘР –** коммуникатив синтаксисның өйрәнү объекты. Сөйләмдә җөмләнең, башка җөмләләр белән бәйләнешкә керүе ягыннан караганда, ике кисәккә бүленүе нигезендә барлыкка килә. Җөмләнең бер өлеше укучы яки тыңлаучы өчен таныш булган күренешләр, вакыйгалар хакында хәбәр итә, икенче өлеше исә яңалык алып килә. Аларның беренчесе – сөйләм предметы яки тема дип, икенчесе сөйләм яңалыгы яки рема дип атала. Татар телендә тема һәм рема ике төрле урнашырга мөмкин: 1) реманы хәбәр яки хәбәр төркеме тәшкил итә. Мәсәлән, *Аның исеме (*тема*) – Гөлия (*рема*). Күрү белән, мин аны (*тема*) таныдым (*рема*)*; 2) рема хәбәр алдында торучы сүз белән бирелә. Мәсәлән, *Без бүген (*тема*) театрга (*рема*) барабыз (*тема*)*. Беренче җөмләдә сөйләм яңалыгы (рема) булган кисәк икенче җөмләдә сөйләм предметына (темага) әйләнә һәм төрле алмашлыклар, синоним сүзләр белән алыштырыла яки шул ук сүз яңадан кабатлана. Мәсәлән, *Менә шуннан китәсең, бара торгач, бер су булыр. Шул суның уртасында утрау булыр. Анда бик юан, бик зур карама үсеп утырыр. Шул карама төбендә...* (әкият)

**АНАЛИТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ –** иярченле кушма җөмләдә баш җөмләгә аналитик чаралар ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмлә. Формасы белән төгәлләнгән була: ия белән хәбәр затта яраша. А.и.ж. һинд-европа телләренең үзенчәлеге булып санала. Мәсәлән, *Мин аны шуның өчен яратам, чөнки ул һәрвакыт дөресен сөйли. Аңлашылды: һөҗүмгә әзерләнәләр икән* (И.Гази). *Чаг.*: **Синтетик иярчен җөмлә.**

**АНАЛИТИК ЧАРА** – аналитик иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртүче чара. А.ч.ларга мөнәсәбәтле сүзләр, иярүче теркәгечләр, аныклаучы теркәгечләр, теркәгеч сүзләр, көттерү һәм аныклау интонацияләре (паузалары) керә. А.ч. я баш җөмләдә урнаша (мөнәсәбәтле сүз, *ки* иярүче теркәгече), я иярчен җөмләнең хәбәреннән читтә тора (иярүче теркәгечләр, теркәгеч сүзләр). *Чаг.*: **Синтетик чара.**

**АНЫКЛАНМЫШ** – аныклагычны ияртеп килгән сүз. *Кара*: **Аныклагыч.**

**АНЫКЛАГЫЧ** – җөмләнең аныклаулы мөнәсәбәт нигезендә барлыкка килә торган иярчен кисәге. А. үзе ияргән сүзгә – анықланмышка – аныклау интонациясе һәм аныклаучы теркәгечләр ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Без, ягъни 10 сыйныф укучылары, конкурска хәзерләнәбез. Изге, шәфкатьле анамыз – мәрхәмәтле җир җылый* (Г.Тукай). Анықланмышка бәйләнү ягыннан А.лар ике төрле була: анықланмышка ярашкан *(Мин озаттым аны сугышка, йөрәгемнең сүнмәс кояшын* (М.Җәлил)*)* һәм анықланмышка ярашмаган *(Дустым Азатка хат яздым)*.

**АНЫКЛАУЛЫ МӨНӘСӘБӘТ** – иярүле бәйләнешкә нигезләнгән һәм бер сүз яки җөмләнең икенчесенә аныклык, өстәмә төгәллек бирүе нәтиҗәсендә барлыкка килә торган мөнәсәбәт. А.м. нигезендә аныклагыч җөмлә кисәге формалаша. А.м.не белдерүдә түбәндәге чаралар катнаша: аныклау интонациясе һәм аныклаучы теркәгечләр.

**АНЫКЛАУЧЫ ТЕРКӘГЕЧ** – аныклаулы мөнәсәбәтне белдерүче чара, аныклагычлар һәм иярчен аныклагыч җөмләләрдә кулланыла. А.т.ләргә *ягъни, мәсәлән, аеруча, аерым әйткәндә, аерым алганда, башкача әйткәндә, икенче төрле әйткәндә, шул исәптән, шул җөмләдән* һ.б. теркәгечләр кертелә.

**АТАУ ҖӨМЛӘ** – бер составлы җөмләнең баш кисәге исем яки исемләшкән сүз төркемнәре белән белдерелгән төре. А.җ.ләр табигать күренешләрен, кешенең килеш-килбәтен, әйләнә-тирә халәтне тасвирлаганда кулланылалар. Мәсәлән, *Төн. Караңгы. Буран. Өермә* (Х.Туфан). *Зур кабинет. Уртада зур өстәл* (К.Тинчурин).

**АТРИБУТ** (лат. *attributum* – өстәлгән, кушылган) – семантик синтаксисның өйрәнү объекты. Традицион (грамматик) синтаксиста аергычка туры килә. *Кара*: **Семантик кисәкләр. Атрибутив мөнәсәбәт.**

**АТРИБУТИВ МӨНӘСӘБӘТ** – сүзтезмәдә ияртүче сүз тарафыннан ияртүченең берәр билгесе, сыйфаты, саны ачыклану нигезендә барлыкка килә торган мөнәсәбәт. Мәсәлән, *кызыклы китап, өч көн, язасы хат, бай кеше.*

**АЧЫКЛАГЫЧ** – семантик синтаксисның өйрәнү объекты. Квалификатор яки конкретизатор дигән атамалары да бар. Традицион (грамматик) синтаксиста хәл кисәкләргә туры килә. *Кара*: **Семантик кисәкләр. Хәл.**

**АЧЫКЛАУЛЫ (ТӨГӘЛЛӘҮЛЕ) МӨНӘСӘБӘТ** – ияртүле бәйләнешкә нигезләнгән һәм бер сүзнең икенчесен ачыклап, конкретлаштырып килүе җирлегендә барлыкка килә торган мөнәсәбәт. А.м. нәтиҗәсендә сүзтезмә формалаша. А.м.не белдерүдә түбәндәге чаралар катнаша: килеш кушымчалары *(бүлмәдә утыру, укудан кайту)*, билгесез килеш формасы *(китап уку, рәсем ясау)*, фигыль формалары *(барачак юл, килгән кунак)*, сыйфат һәм рәвеш ясагыч кушымчалар *(баллы чәй, төлкедәй хәйләкәр)*, сан төркемчәләре кушымчалары *(өченче урын, бишәр дәфтәр)*, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр *(дусты белән бару, кара дип әйтү)*, сүзләрне кабатлау *(чиләк-чиләк җиләк, мичкә-мичкә бал)*, фраза басымы, сүз тәртибе *(матур чәчәк, көчле егет)*, янәшә тору *(иртә кайту, кызу йөрү)*, лексик мәгънә *(бүген* кич белән концертка *бару).*

Кайбер дәреслекләрдә шулай ук ияртүче теркәгечләр, теркәгеч сүзләр һәм мөнәсәбәтле сүзләр дә *(килмәдем, чөнки авырдым; кем эшләми, шул ашамый* (мәкаль)*)* А.м.не белдерүче чараларга кертелә.

## Б

**БАШ ҖӨМЛӘ –** иярченле кушма җөмләнең иярчен җөмлә тарафыннан ачыкланып килә торган һәм чагыштырмача бәйсез компоненты. Мәсәлән, *Укытучы бүлмәгә кергәч, дәрес башланды*.

**БАШ КИСӘКЛӘР –** җөмләнең хәбәрлеген, оештыручы үзәген тәшкил итүче кисәкләр (*Кара*: **Хәбәрлек**). Баш кисәкләргә ия һәм хәбәр керә.

**БАШ ХӘРЕФ –** җөмлә һәм ялгызлык исемнәр башында, кайбер шартлы билгеләрдә һәм кыскартылма сүзләрдә, шулай ук III зат күплектә ихтирамны белдерү өчен кулланыла торган махсус хәреф. Мәсәлән, *Казан шәһәре, Идел елгасы; КДУ, БМО, БДБ; Салих әфәнде, Сезгә мөрәҗәгать итәргә мөмкинме?*

**БЕР-БЕР АРТЛЫ ИЯРҮЛЕ ҖӨМЛӘ.** *Кара*: **Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**

**БЕРНИЧӘ ТӨР ИЯРҮЛЕ ҖӨМЛӘ.** *Кара*: **Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**

**БЕР СОСТАВЛЫ ҖӨМЛӘ –** җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең бер генә баш кисәге булган һәм икенчесен куеп карарга мөмкин булмаган төре. *Чаг.*: **Ике составлы җөмлә**. Бер составлы җөмләләргә атау җөмлә, билгеле үтәүчеле, билгесез үтәүчеле, гомуми үтәүчеле, үтәүчесез фигыль җөмләләр керә.

**БИЛГЕЛЕ ҮТӘҮЧЕЛЕ ҖӨМЛӘ** – бер составлы гади җөмләнең баш кисәге фигыль белән белдерелеп, үтәүчесе иялек, юнәлеш килешендәге сүзләрдән, фигыль формаларыннан яки контексттан аңлашылган төре. Мәсәлән, *Бу спектакльне караганыбыз бар. Өйгә кайтып килешем. Йоклап кителгән. Сиңа укыштыргаларга кирәк булыр* (Ә.Фәйзи).

**БИЛГЕСЕЗ КИЛЕШ ФОРМАСЫ** – сүзнең баш килештәге, ләкин төшем яки иялек килешенә куеп карарга мөмкин булган формасы. Мәсәлән, *китап (китапны) уку, рәсем (рәсемне) ясау, мәктәп (мәктәпнең) бакчасы, егет (егетнең) сүзе.*

**БИЛГЕСЕЗ ҮТӘҮЧЕЛЕ ҖӨМЛӘ** – бер составлы гади җөмләнең баш кисәге фигыль белән белдерелеп, үтәүчесе әйтелмәгән яки контексттан билгеле булмаган төре. Билгесез үтәүчеле җөмләнең баш кисәге III зат хикәя яки шарт фигыльнең күплеге белән белдерелә. Мәсәлән, *Фәхрине яраталар иде* (Г.Ибраһимов). *Сиңа миннән хәбәр китерсәләр, илен саткан Муса, дисәләр…* (М.Җәлил). *Аны бүлек башлыгы итеп билгеләгәннәр.*

**БОЕРЫК (ӨНДӘҮ) ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең әйтү максаты ягыннан аерылган төре. Кемне яки нәрсәне дә булса эшкә өндәү, кушу, ихтыярны белдерү өчен кулланыла. Б.җ.гә боеру интонациясе хас, хәбәре күп очракта боерык фигыль, инфинитив формалары белән белдерелә. Мәсәлән, *Ерак китәсе булма! Ялкауланмаска, артта калмаска!*

**В**

**ВАКЫТ ХӘЛЕ** – хәл иярчен кисәгенең процессның яки билгенең үтәлү вакытын белдерә торган төркемчәсе. Ияртүче сүзгә урын-вакыт, төшем, чыгыш

килеше кушымчалары, бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(белән, соң, арада, чакта, вакытта, алдыннан һ.б.)*, төрле фигыль формалары аша яки янәшә торып бәйләнә. Мәсәлән, *1987 нче елда туу, шул көнне килү, иртән бару, ике сәгатьтән килеп җитү, кич белән очрашу, кайтыр алдыннан сөйләшү, ишеткәннән соң шатлану, баргач күрү, быел тәмамлау.*

**ВАРИАТИВ СИНТАКСИС (ВАРИАНТЛАР СИНТАКСИСЫ) –** – синтаксисның бер юнәлеше, синтаксик берәмлекләрнең вариантларын өйрәнә. Әдәби норма булып җитмәгән, диалектларда, аерым кешеләр сөйләмендә генә кулланыла торган вариантларны да тикшерү объекты итеп ала.

**ВОКАТИВ ҖӨМЛӘ** – сүз җөмләләрнең тойгылы интонация белән әйтелгән һәм бары тик исем белән генә белдерелгән төре. Мәсәлән, *И кызым... Мин, ... нишләргә белмичә, «Әни!» дип кычкырып җибәрдем* (М.Әмир).

## Г

**ГАДӘТИ ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең тыныч интонация белән, тойгы катнашмыйча әйтелгән төре. Г.җ.гә туры сүз тәртибе хас. Мәсәлән, *Дәресләрдән соң китапханәгә кердек. Чаг.*: **Тойгылы җөмлә.**

**ГАДИ ҖӨМЛӘ** – бер хәбәрлеккә ия булган җөмлә. *Кара*: **Җөмләләрне төркемләү.** *Чаг.*: **Кушма җөмлә.**

**ГИПОТАКСИС** (гр. *hypo* – аста, *taxis* – урнашу). *Кара*: **Ияртүле бәйләнеш.**

**ГОМУМИЛӘШТЕРҮЧЕ СҮЗ** – тиңдәш кисәкләрне бергә җыеп, мәгънәләрен гомумиләштереп килә торган кисәк. Билгеләү яки юклык

алмашлыклары белән белдерелә. Тиңдәш кисәкләр белән бер үк синтаксик функцияне үти. Мәсәлән, *Менә бу кошлар сайравы да, татлы каен суы һәм яшел яфраклар исе дә, ... бу дымсу урман һавасы да – бөтенесе дә аңа тансык, ул аларның һәммәсен дә сагынган иде* (Г.Бәширов). *Барысы да: әти-әнисе, абыйлары, апалары, Зөфәр өстәл янында җыелып утыралар* (Ф.Садриев).

**ГОМУМИ ҮТӘҮЧЕЛЕ ҖӨМЛӘ** – бер составлы гади җөмләнең баш кисәге фигыль белән белдерелеп, үтәүчесе гомумиләшкән затка караган төре. Баш кисәге II зат боерык, шарт яки хикәя фигыль формалары, *-ып/-еп/-п була*, *-ырлык (түгел)*, *-малы (түгел)* формалы фигыльләр, сирәк очракларда III зат күплек сандагы хикәя фигыль формасы белән белдерелә. Г.ү.җ. мәкаль-әйтемнәрдә һәм сөйләм телендә еш кулланыла. Мәсәлән, *Аз сөйлә, күп эшлә* (мәкаль). *Урамга чыгарлык түгел. Урманга керәсең, киң итеп сулыйсың...* (М.Мәһдиев) *Ни чәчсәң, шуны урырсың* (мәкаль). *Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар* (мәкаль).

**ГРАММАТИК ТАРКАЛА ТОРГАН ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибы нигезендә (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү)**, аерым җөмлә кисәкләренә таркала алучы җөмлә төре. *Чаг.*: **Грамматик таркалмый торган җөмлә.**

**ГРАММАТИК ТАРКАЛМЫЙ ТОРГАН ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү)**, аерым җөмлә кисәкләренә таркатып булмый торган җөмлә төре. Әлеге җөмләләргә хәбәрлек сүзләр, ымлыклар, аваз ияртемнәре, кисәкчәләр белән бирелгән, ягъни сүз җөмләләр керә. Мәсәлән, *Әйе. Юк. Аһ! Ух! Инде... Чаг.*: **Грамматик таркала торган җөмлә.**

## Д

**ДЕТЕРМИНАНТЛАР** (лат. *determinans (determinantis)* – билгеләүче) **–** җөмләне җәенкеләндерүче, аның аерым бер кисәге белән дә бәйләнмәгән, тулаем җөмләгә карый торган иярчен кисәк. Мәсәлән, *Аңа пенсиягә кадәр бер ел!* Татар тел белемендә М.З.Зәкиев Д.ны «җөмлә башына чыгарып әйтелгән һәм сөйләм предметын белдерә торган тәмамлыклар һәм хәлләр» дип билгели. Мәсәлән, *Казан урамнарын ташлап китәм* (Һ.Такташ). *Иртә белән көн томанлы иде* (Ш.Камал).

**ДИАЛЕКТАЛЬ СИНТАКСИС** (гр. *dialektos* – сөйләшү; сөйләш, шивә; *syntaxic* – төзелеш**)** **–** синтаксисның бер юнәлеше, билгеле бер диалекттагы җирле сөйләмнең синтаксик төзелешен өйрәнә.

**ДИАЛОГ** (гр. *dia* – аша, аркылы, *logos* – сөйләшү) **–** туры сөйләмнең бер төре, әдәби әсәрдә ике яки берничә кешенең кара-каршы сөйләшүен биргән өлеш. Мәсәлән,

— *Зиннәт кайда?*

— *Урманда, эштә.*

— *Шакир абый?*

— *Ул да шунда* (К.Тинчурин).

## Җ

**ҖӘЕНКЕ ҖӨМЛӘ** **–** җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү)**, баш һәм иярчен кисәкләре булган гади җөмлә төре. Мәсәлән, *Табигать бик матур. Без бүген килдек. Чаг.*: **Җыйнак җөмлә.**

**ҖӘЯЛӘР** – текстның төп өлешенә өстәмә мәгълүмат яки аныклык керткән сүз, сүзтезмә яисә җөмләләрне аерып кую өчен кулланыла торган тыныш билгесе. Мәсәлән, *Җавап көтмичә, кулындагы чәчәкләр бәйләмен (букетын) Хәятка сонды (тәкъдим итте)* (Ф.Әмирхан). Лингвистик текстларда Җ. тыныш билгесе буларак кына түгел, шартлы язуны белдерү өчен дә файдаланыла. Мәсәлән, фонетик транскрипция квадрат җәяләрдә бирелә: *толым [толом],* фонологик – гадәттә кыек җәяләрдә: *шөбһә /шөпһә'/*, сирәгрәк почмаклы җәяләрдә языла: *кадер <ķ$^{a}$әдėр>*.

**ҖӨМЛӘ** – хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә барлыкка килә торган төп синтаксик берәмлек, тәмамланган уйны белдерүче сүз яки сүзләр тезмәсе. Җ.нең төп билгеләре: хәбәр итү (предикативлык), модальлек, билгеле бер интонация белән әйтелү, шушы телгә хас булган үзенчәлекле сүз тәртибенә ия булу.

**ҖӨМЛӘДӘ СҮЗ ТӘРТИБЕ** – җөмләнең бер үзенчәлеге, аерым тел яки телләр төркемендә сүзләрнең билгеле бер тәртиптә урнашуы. Нинди сөйләмдә һәм стильдә кулланылуына карап, сүз тәртибе ике төрле була: сүзләрнең туры (уңай) тәртибе һәм сүзләрнең кире тәртибе, ягъни инверсия.

**ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕ** – җөмләнең мөстәкыйль мәгънәле сүзләр (яки мөстәкыйль мәгънәле һәм ярдәмлек сүзләр) белән белдерелгән, формаль һәм мәгънәви билгеләренә нигезләнеп аерылган кисәкләр. Җөмләнең баш, иярчен һәм модаль кисәкләрен билгелиләр. *Кара*: **Баш кисәкләр. Иярчен кисәкләр. Модаль кисәкләр.**

**ҖӨМЛӘЛӘРНЕ ТӨРКЕМЛӘҮ.** Җөмләләр түбәндәге принципларга нигезләнеп төркемләнәләр: 1) хәбәрлекнең ничә булуына карап, гади җөмлә һәм кушма җөмлә; 2) хәбәрлекнең ничек белдерелүенә карап, ике составлы җөмлә һәм бер составлы җөмлә; 3) мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган

кисәкләрнең булу яки булмавына карап, тулы җөмлә һәм ким җөмлә; 4) әйтү максатына бәйле рәвештә, хикәя, сорау яки боерык (өндәү) җөмләләр; 5) тойгының катнашу яки катнашмавына карап, тойгылы җөмлә һәм гадәти (тойгысыз) җөмлә; 6) чынбарлыктагы күренешләрне раслау яки кире кагуга карап, раслау җөмлә һәм инкяр җөмлә; 7) иярчен кисәкләрнең булу яки булмавына бәйле рәвештә, җыйнак җөмлә һәм җәенке җөмлә; 8) аерым җөмлә кисәкләренә таркала алу яки алмауга карап, грамматик таркала торган җөмлә һәм грамматик таркалмый торган җөмлә.

**ҖЫЙНАК ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү)**, баш кисәкләре генә булган гади җөмлә төре. Мәсәлән, *Табигать матур. Без килдек. Чаг.*: **Җәенке җөмлә.**

## З

**ЗУР ХӘРЕФ.** *Кара*: **Баш хәреф.**

## И

**ИКЕ НОКТА (:)** – гади һәм кушма җөмләдә кулланыла торган тыныш билгесе. Гади җөмләдә тиңдәш кисәкләрдән алда килгән гомумиләштерүче сүздән соң (*Монда һәрнәрсә ак бит: урын-җир, стена, түшәм, тәрәзә яңаклары…* (Б.Камалов)*)*, фигыль белән бирелгән аныкланмыштан соң (*Кинәт көн әллә нишләде: сүнеп, сүрелеп калгандай булды* (М.Галиев)*)*; кушма җөмләдә мөнәсәбәтле сүзе булган баш җөмлә алдан килгән яки күтәрү интонациясе аша бәйләнгән иярченле кушма җөмләләрдә *(Кеше күңеле дә шулай: яраны, озак та үтми, башка хисләр күмеп, төреп ала* (М.Мәһдиев). *Сизелә: үтте яшь вакытлар* (Г.Тукай)*)*; теземдә төп бүлек санау бүлегеннән алда килгәндә куела.

**ИКЕ СОСТАВЛЫ ҖӨМЛӘЛӘР** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү)**, ике баш кисәге дә булган яки икенчесен куеп карау мөмкинлеге табылган гади җөмлә төре. Мәсәлән, *Мин җиңел генә тордым. Юындым* (М.Әмир). *Чаг.*: **Бер составлы җөмлә.**

**ИНВЕРСИЯ** (лат. *inversio* – әйләндерү, күчереп (алмаштырып) кую) – җөмләдә сүз тәртибенең җанлы сөйләмдә, поэзиядә, тойгылы җөмләләрдә кулланыла торган төре. Кире тәртиптә сүзләр түбәндәгечә урнашалар: 1) хәбәр иядән алда килә. Мәсәлән, *Шаулый диңгез... Җил өрәдер... Җилкәнен киргән кораб!* (Дәрдемәнд); 2) аергыч аерылмыштан, тәмамлык һәм хәлләр үзләре ияргән сүздән соң урнашалар. Мәсәлән, *Хуш, иске ел, көмеш сакаллы!* (М.Җәлил) *Ник моңарчы әйтмәдегез аны?* (Ә.Гаффар) *Төште очкын күңелгә* (Р.Төхфәтуллин). Аныклагыч белән аныкланмыш арасында һәм модаль кисәкләрдә И. күренеше булмый. *Чаг.*: **Сүзләрнең туры (уңай) тәртибе.**

**ИНКАРЬ ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең чынбарлыктагы күренешләрне кире кагуга нигезләнгән төре. И.җ. күрсәткечләре: фигыльләрдә – *-ма/-мә, -м*, сыйфатларда – *-сыз/-сез* кушымчалары; *түгел* кисәкчәсе; *юк* хәбәрлек сүзе. Мәсәлән, *Минем анда барганым юк. Көн болытсыз. Алар килмәделәр. Бу китап минеке түгел.* Сөйләм телендә инкарь мәгънәсе махсус күрсәткечләр булмаганда да белдерелә ала. Мәсәлән, *Бара ди! Барды ди! Барган ди! Кая инде ул бару! Барды сиңа! Баргандыр! Барыр ди! Нинди бару!* *һ.б. Чаг.*: **Раслау җөмлә.**

**ИЯ** – ике составлы җөмләнең яки бер составлы атау җөмләнең баш кисәге, икенче баш кисәк – хәбәр белән хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә бәйләнә. Ия җөмләнең абсолют бәйсез кисәге дип санала. Барлык сүз төркемнәре белән дә белдерелә ала. Төзелеше буенча гади һәм тезмә ияләр

билгеләнә. Мәсәлән, *Һавада берөзлексез тургайлар сайрый* (Ф.Шәфигуллин). *Тырышкан табар, ташка кадак кагар* (мәкаль). *Урманда каен җиләкләре өлгергән. Казан дәүләт университеты 1804 нче елда ачылган.*

**ИЯРТҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ** – бер сүз яки җөмләнең икенчесенә буйсынуы нигезендә барлыкка килә торган бәйләнеш. Ияртүле бәйләнештә өч төрле мөнәсәбәт булырга мөмкин: хәбәрлекле мөнәсәбәт, ачыклаулы (төгәлләүле) мөнәсәбәт һәм аныклаулы мөнәсәбәт. *Чаг.*: **Тезүле бәйләнеш.**

**ИЯРЧЕН АЕРГЫЧ ҖӨМЛӘ** – баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән аергычны ачыклый яки баш җөмләнең аергычы урынында килә торган иярчен җөмлә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.а.җ. баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шул, шундый, мондый, шушы, шуның, моның, бер һ.б.; нинди – шундый, кайсы – шул, кем – шул һ.б.)*, күтәрү интонациясе (паузасы), *ки* ияртүче теркәгече ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Бәхетле шул баладыр, кайсы дәресенә күңел бирсә* (Г.Тукай). *Бар шундый кешеләр: яхшылык эшләгән өчен дә рәхмәт әйтмиләр* (М.Әмир). Синтетик И.а.җ. баш җөмләгә янәшә тору чарасы, сыйфат фигыль формалары, иялек килеше кушымчасы, сүз ясагыч кушымчалар (*-лы/-ле, -сыз/-сез, -дагы/-дәге, -дай/-дәй, -лык/-лек)*, бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(дигән, кебек, шикелле, сыман, хәтле, чаклы, кадәрле)* аша ияртә. Мәсәлән, *Бәя җитмәс кешеләр сез* (Р.Фәйзуллин). *«Нишләргә соң?» дигән сорау белән киләм синең рәсмең каршына* (Х.Туфан). *Күңеле пакь кеше кайгысыз яши* (мәкаль).

**ИЯРЧЕН АНЫКЛАГЫЧ ҖӨМЛӘ** – иярчен җөмләнең баш җөмләдәге берәр төшенчә яки фикерне аныклап килә торган төре. Аналитик төре генә бар, баш җөмләгә аныклау интонациясе (паузасы) яки аныклаучы теркәгечләр

*(ягъни, аеруча, бигрәк тә, дөресрәге, хәтта, икенче төрле әйткәндә, башкача әйткәндә һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара**). Мәсәлән, *Телдән әйтә алмаган куанычым бик зур: ул мине үз итә, якын итә* (Ә.Еники). *Урынымнан торып, сихерле һәм нурлы якка, ягъни теге кыз утырган җиргә елыштым* (И.Гази). *Мостафин бу урыннан очып төште, башкача әйткәндә, аны яңадан сайламадылар* (Ә.Еники).

**ИЯРЧЕН ВАКЫТ ҖӨМЛӘ** – баш җөмләдәге эш яки хәлнең үтәлү вакытын белдерә торган иярчен җөмлә. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклый яки баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.в.җ. баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шул вакытта, шул чакта, шунда, шуннан соң, аңа кадәр, аннары һ.б.; кайчан – шунда, кайчан – шул вакытта, кайчан – шул чакта һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Әз генә бер куанычың булырга өлгерми, шунда ук хәсрәт килеп баса* (Ш.Маннур). *Сәгать ничәгә чакырсаң, шул вакытка килермен.* Синтетик И.в.җ. баш җөмләгә хәл фигыль формалары *(-гач/-гәч, -ганчы/-гәнче)*, хәбәр составындагы урын-вакыт яки иялек килеше кушымчалары, бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(вакытта, чакта, арада, мәлдә, борын, соң, бирле, саен һ.б.)* аша ияра. Мәсәлән, *Сугыш беткәч, батыр күбәя* (мәкаль). *Син барда мин һәрчак дулкынланам* (Р.Фәйзуллин). *Туган телең искә төшә икән, хәл ителгән чакта язмышлар* (С.Хәким).

**ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ** – иярченле кушма җөмләдә баш җөмләгә ияреп, буйсынып килгән җөмлә. Төзелешләре ягыннан иярчен җөмләләр ике төргә бүленә: синтетик иярчен җөмлә һәм аналитик иярчен җөмлә. Мәгънәләре буенча иярчен җөмләләрнең түбәндәге төрләре була: иярчен ия җөмлә, иярчен хәбәр җөмлә, иярчен аергыч җөмлә, иярчен тәмамлык җөмлә, иярчен хәл җөмләләр (иярчен урын җөмлә, иярчен вакыт җөмлә,

иярчен сәбәп җөмлә, иярчен максат җөмлә, иярчен күләм җөмлә, иярчен рәвеш җөмлә, иярчен шарт җөмлә, иярчен кире җөмлә) һәм иярчен аныклагыч җөмләләр.

**ИЯРЧЕН ИЯ ҖӨМЛӘ** – баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән ияне ачыклый яки баш җөмләнең иясе урынында килә торган иярчен җөмлә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.и.җ. баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шул, бу, ул, шунысы, монысы, анысы, шушы, бер нәрсә һ.б.; кем – шул, кемнең – шул, нәрсә - шул, нинди – шул, кайсы – шунысы һ.б.)*, көттерү интонациясе (паузасы), *ки* ияртүче теркәгече ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Кемгә әйтсәң, шул барыр* (И.Гази). *Һәркемгә билгеле: Тукай бик принципиаль кеше булган* (С.Кудаш). Синтетик төре баш җөмләгә янәшә тору чарасы, бәйлек сүзләр *(дию, дигән)*, кайбер сүз ясагыч кушымчалар *(-лык/-лек, -лы/-ле, -сыз/-сез)* аша иярә. Мәсәлән, *Бәхете бар үзенә тиңне иптәш итә* (мәкаль). *Канаты бар очар* (мәкаль). *Аны акча юклык борчый. Әти киләчәк дию әле берни дә аңлатмый* (М.Хәсәнов).

**ИЯРЧЕН КҮЛӘМ ҖӨМЛӘ** – баш җөмләдәге билгенең яки процессның күләмен, дәрәҗәсен белдерә торган иярчен җөмлә. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән күләм хәлен ачыклый яки баш җөмләнең күләм хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.к.җ. баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шундый, шул дәрәҗәдә, шул хәтле, шулкадәр, шулай, алай һ.б.; никадәр – шулкадәр, күпме – шул хәтле, ничаклы – шулчаклы һ.б.)*, *ки* ияртүче теркәгече ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Бу вакытта Ләйлә шулкадәр матур иде ки, аңа бөтен кешенең исе китә иде* (И.Гази). *Ни хәтле тиз булса, шул хәтле яхшы* (Ш.Камал). Синтетик И.к.җ. баш җөмләгә хәл фигыль формасы *(-ганчы/-гәнче)*,

бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(кадәр, чаклы, хәтле, саен, дәрәҗәдә һ.б.)* аша иярә. Мәсәлән, *Үз кадерен белмәгән кеше кунакта кадере беткәнче утырыр* (мәкаль). *Көчем җиткән кадәрле тырышырмын* (М.Әмир). *Хәзер инде хәлләр сукырлар да күрерлек дәрәҗәдә ачылды* (Г.Ибраһимов).

**ИЯРЧЕН КИРЕ ҖӨМЛӘ** – баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең киресе булачагын белдерә торган иярчен җөмлә. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән кире хәлне ачыклый яки баш җөмләнең кире хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.к.ж. баш җөмләгә ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр *(шулай да, алай да, шулай булса да, шуңа карамастан һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Мәкалә әйбәт кенә булды кебек, шулай да тагын бер кат карап чыгасы иде. Машинаны йөртү бик кыен, шулай булса да син бу эшкә көннән-көн ияләнә барасың* (Г.Тукай). Синтетик И.к.ж. баш җөмләгә шарт фигыль формасы һәм *да/дә* кисәкчәсе, хәл фигыль формалары *(-ып/-еп/-п, -гач/-гәч)* һәм *да/дә* кисәкчәсе, боерык фигыль формасы *(-сын/-сен),* исем фигыль формасы һәм *белән* бәйлеге, *карамастан* бәйлек сүзе аша иярә. Мәсәлән, *Син үзең карагач та, мин берни дә күрмәгән бит* (К.Тинчурин). *Кулымны бәйләсәләр дә, телемне бәйләтмәдем* (Х.Туфан). *Уянмый ул, бөтен кеше тавышлансын* (Г.Тукай).

**ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘР** – җөмләнең баш кисәкләренә ияреп килгән, төрле формаль һәм мәгънәви билгеләре нигезендә аерылган кисәкләр. И.к.гә аергыч, тәмамлык, хәлләр (урын хәле, вакыт хәле, сәбәп хәле, максат хәле, күләм хәле, рәвеш хәле, шарт хәле, кире хәл) һәм аныклагыч керә.

**ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘ** – кушма җөмләнең аерым җөмләләре үзара ияртү юлы белән бәйләнгән төре (*Кара*: **Ияртүле бәйләнеш**). Ияртүче җөмлә баш җөмлә дип, ияреп килгәне иярчен җөмлә дип йөртелә. Татар телендә иярченле кушма җөмләләр төзелешләре ягыннан ике төргә бүленәләр: синтетик

иярченле кушма җөмлә һәм аналитик иярченле кушма җөмлә. *Кара*: **Синтетик җөмлә. Аналитик җөмлә.**

**ИЯРЧЕН МАКСАТ ҖӨМЛӘ** – иярчен җөмләнең баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең максатын белдерә торган төре. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән максат хәлен ачыклый яки баш җөмләнең максат хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.м.ж. баш җөмләгә ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр *(шуның өчен, моның өчен, аның өчен һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Безгә тынычлык шуның өчен кирәк: без киләчәктә тыныч тормыш төзергә телибез* (Р.Сибат). Синтетик И.м.җ. баш җөмләгә *өчен* бәйлеге яки *дип* бәйлек сүзе аша иярә. Мәсәлән, *Кыз уянмасын өчен, һәркем аяк очы белән басып йөри* (Ш.Камал). *Илеңдә иминлек булсын дип, тәнеңә изге саф җан иңгән* (И.Иксанова).

**ИЯРЧЕН РӘВЕШ ҖӨМЛӘ** – баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең үтәлү рәвешен белдерә торган иярчен җөмлә. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән рәвеш хәлен ачыклый яки баш җөмләнең рәвеш хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.р.ж. баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шулай, алай, шул рәвешчә, шулай итеп, шундый итеп һ.б.; ничек – шулай, ничек – шулай итеп, ничек – шул рәвешчә һ.б.)*, ияртүче теркәгечләр *(гүя, гүя ки, әйтерсең, диярсең һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Җиңел сөякле Кутуй белән салмак хәрәкәтле Такташ гел бер-берсенә тагылып йөриләр, шулай калган минем хәтеремдә* (Ә.Еники). *Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза* (мәкаль). *Болын бүген тыныч, хуш исле, ислемай сипкәннәр диярсең* (Г.Әпсәләмов). Синтетик И.р.ж. баш җөмләгә бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(кебек, шикелле, төсле, сыман, кук, хәлдә, килеш, итеп, дип һ.б.)*, рәвеш ясагыч

кушымчалар *(-ча/-чә, -дай/-дәй)*, хәл фигыль формасы *(-ып/-еп/-п)*, *-мыни/-мени* сорау кушымчасы аша иярә. Мәсәлән, *Ул, күзләре еракларга текәлгән килеш, туган ил табигатенең гүзәллегенә сокланып торды* (М.Әмир). *Вөҗданым кушканча яшим* (Р.Фәйзуллин). *Ачылды, кар эреп, таулар, тугайлар* (Дәрдемәнд).

**ИЯРЧЕН СӘБӘП ҖӨМЛӘ –** баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең үтәлү сәбәбен белдерә торган иярчен җөмлә. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән сәбәп хәлен ачыклый яки баш җөмләнең сәбәп хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.с.ж. баш җөмләгә ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр *(шуңа, шуңа күрә, шул сәбәпле, шунлыктан, шуның аркасында, шуның өчен һ.б.)*, көттерү интонациясе (паузасы), ияртүче теркәгечләр *(чөнки, ки, ник дисәң, ник дигәндә һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Мәк чәчәген өздем ялгыш кына, күз яшьләре түктең син шуңа* (Г.Зәйнашева). *Гаҗиз калды доктор: авыру кызга бер дару да файда бирмәде* (М.Җәлил). Синтетик И.с.ж. баш җөмләгә бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(күрә, сәбәпле, аркасында, өчен, дип һ.б.)*, юнәлеш яки чыгыш килеше кушымчалары, хәл фигыль формалары *(-гач/-гәч, -ып/-еп/-п)* аша иярә. Мәсәлән, *Кеше күп булганга күрә кермәдек* (А.Расих). *Яңгыр юктан бар җир кипте, корды* (Р.Фәйзуллин). *Әтием өйдә булмагач, бу юлы мин аны үзем озата чыктым* (Ә.Еники).

**ИЯРЧЕН ТӘМАМЛЫК ҖӨМЛӘ –** иярчен җөмләнең баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкны ачыклый яки баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килә торган төре. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.т.ж. баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шуны, моны, шунысын, монысын, шуңа, шуннан, шуның белән, шул турыда, шул хакта һ.б.; ни – шуны, кемнән – шуннан, кем – шуңа*

*һ.б.)*, көттерү интонациясе (паузасы), *ки* ияртүче теркәгече ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Зур бурычлар тора алгы көндә, шул турыда язып ташлыймын* (Һ.Такташ). *Яулык шаһит: сине һәм илемне йөрәк каным белән саклaдым* (М.Җәлил). Синтетик И.т.ж. баш җөмләгә төшем, юнәлеш, иялек, чыгыш яки урын-вакыт килеше кушымчалары, бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(турында, хакында, белән, дип һ.б.)* аша иярә. Мәсәлән, *Тел әйтә алмаганны җыр әйтер* (мәкаль). *Син шундый ачык һәм матур язасың дип, һич тә күз алдыма китермәгән идем* (С.Әдһәмова).

**ИЯРЧЕН УРЫН ҖӨМЛӘ** – иярчен җөмләнең баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең үтәлү урынын белдерә торган төре. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән урын хәлен ачыклый яки баш җөмләнең урын хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.у.ж. баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шунда, анда, шул урында, шул җирдә, шул якта һ.б.; кайда – шунда, каян – шуннан, кая – шунда һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена* (җыр). *Ул җырны кайда ишетсәң, туган ил шунда булыр* (Рәшит Әхмәтҗанов). Синтетик И.у.ж. баш җөмләгә бәйлек сүзләр *(урында, җирдә, якта, якка, яктан һ.б.)* аша иярә. Мәсәлән, *Изгелек беткән җирдә явызлык башлана* (мәкаль). *Мин ул киткән якка карап калдым.*

**ИЯРЧЕН ХӘБӘР ҖӨМЛӘ** – баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән хәбәрне ачыклый яки баш җөмләдә бирелмәгән хәбәр урынында килә торган иярчен җөмлә. Бары аналитик төре генә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара**). Баш җөмләгә ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр *(шул, бу, шулай, шундый, шунда, шул иде, шул булды, шул хәтле һ.б.; кем – шул, ничек – шулай, күпме – шул кадәрле һ.б.)*, көттерү интонациясе (паузасы), *ки* ияртүче теркәгече ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Дөньясы шундый: күп бүген хиссезләр, эшкуарлар* (Р.Гаташ). *Күпме булса сездә көч һәм ялкын, шул*

*кадәрле җирдә хаккыгыз* (М.Җәлил). *Сиңа сүз шул ки, бу серне кешегә сөйләмә* (Г.Тукай).

**ИЯРЧЕН ХӘЛ ҖӨМЛӘЛӘР** – баш җөмләгә ияреп, аны төрле яклап ачыклаучы җөмләләр. Мәгънәләре буенча 8 төргә бүленәләр. *Кара*: **Иярчен урын җөмлә. Иярчен вакыт җөмлә. Иярчен сәбәп җөмлә. Иярчен максат җөмлә. Иярчен күләм җөмлә. Иярчен рәвеш җөмлә. Иярчен шарт җөмлә. Иярчен кире җөмлә.**

**ИЯРЧЕН ШАРТ ҖӨМЛӘ** – иярчен җөмләнең баш җөмләдән аңлашылган эш яки хәлнең үтәлү шартын белдерә торган төре. Баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән шарт хәлен ачыклый яки баш җөмләнең шарт хәле урынында килә. Аналитик төре дә, синтетик төре дә бар (*Кара*: **Аналитик иярчен җөмлә. Аналитик чара. Синтетик иярчен җөмлә. Синтетик чара**). Аналитик И.ш.җ. баш җөмләгә ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр *(шулай булса, алай булса, алайса, юкса, югыйсә, шулай булганда һ.б.)* ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *Дөресен әйтик, юкса ул яратмас. Арамыздан китәрелсен яман эшләр, шулай булса алга китәр тәмам эшләр* (Г.Тукай). Синтетик И.ш.җ. баш җөмләгә шарт фигыль формасы, *-мы/-ме* сорау кушымчасы, боерык фигыль формасы *(сын/-сен)*, урын-вакыт килешендәге үткән заман сыйфат фигыль формасы *(-ганда/-гәндә)*, бәйлек сүзләр *(исә, икән)* аша иярә. Мәсәлән, *Башың эшләмәсә, аягың күп йөрер* (мәкаль). *Буш вакыт булдымы, Иделгә куна китәләр* (Г.Ибраһимов). *Ныклабрак уйлап караганда, ул, чыннан да, гаепле түгел иде* (Г.Ибраһимов).

## К

**КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ** – икедән артык хәбәрлеге булган кушма җөмлә. Төзелеше буенча өч төргә бүленә: күп тезмәле катлаулы

кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә һәм катнаш кушма җөмлә**.**

**КАТНАШ КУШМА ҖӨМЛӘ** – катлаулы кушма җөмләнең бер төре, аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән җөмлә, ягъни кимендә ике баш җөмләгә бер яки күбрәк иярчен җөмлә бәйләнеп килү нигезендә формалашкан җөмлә. Мәсәлән, *Мин аны бик сөямен дә, ләкин күңелем сизәдер ки, мин бу эшкә ярамыйм* (Г.Тукай). *Офык киңәйгән саен, сүз күбәя, сөйләшүләр кызыграк була бара* (А.Гыйләҗев).

**КВАЛИФИКАТОР.** *Кара*: **Ачыклагыч.**

**КЕРЕШМӘ** – грамматик яктан формалашкан җөмлә уртасына яки сирәк кенә ахырына килеп кергән, төп җөмлә турында өстәмә мәгълүмат биргән җөмлә. М.З.Зәкиев иярчен кереш җөмлә дип атый. Гадәттә җәяләр эчендә бирелә, сирәк кенә сызыклар белән аерылырга мөмкин. Мәсәлән, *Каршымда уртачадан тәбәнәгрәк (элек ул шактый озын булып күренә иде) кеше басып тора* (М.Юныс). *Язучы кеше (иҗат кешеләре барысы да шундый дип уйлыйм) – бертуктаусыз уйлана-эзләнә торган җан ул* (И.Гази). *Хәзер ике татар очрашканда, бер-берсе белән үз телләрендә иркенләп сөйләшәләр (!)* (Р.Әхмәтҗанов). *Хәлил агай, йотлыгып-йотлыгып – җаны әрнеп булыр – шуларны хикәя кылды* (Ш.Камал).

**КЕРЕШ СҮЗ** – сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә төрле мөнәсәбәтен белдерүче модаль кисәк. К.с.ләр күп төрле мәгънә аңлатырга мөмкин: фикернең чыганагы (*минемчә, синеңчә, безнеңчә һ.б.)*, фикернең тәртибе *(беренчедән, икенчедән, бердән һ.б.)*, шикләнү *(бәлки, ихтимал, күрәсең, ахры, ахрысы һ.б.)*, шикләнмәслек итеп әйтү *(әлбәттә, һичшиксез, шөбһәсез, билгеле, бәхәссез, дөрес, чынлап та һ.б.)*, фикернең гадәтилеге *(гадәттә, табигый, билгеле булганча, гадәт буенча, кабул ителгәнчә һ.б.)*, игътибарны җәлеп итү *(тукта*

*(әле), гафу ит, кара (әле), әйтсәм әйтим, беләсең килсә һ.б.)*, үтенү *(зинһар)*, бәя бирү *(дөресен әйткәндә, дөресрәге, иң яхшысы, турысын әйткәндә, иң әһәмиятлесе, иң мөһиме һ.б.)*, төрле тойгылар, эмоциональ мөнәсәбәт *(бәхеткә (каршы), кызганычка (каршы), имеш, янәсе һ.б.)*, фактларны акылга алу, аңлау *(мисал өчен, мәсәлән, әйтик, фараз итик һ.б.)*, фикерне йомгаклау, нәтиҗә ясау *(димәк, шулай итеп, нәтиҗә ясап әйткәндә, йомгаклап әйткәндә, ниһаять, күренгәнчә, кыскасы, гомумән, гомумиләштереп әйткәндә һ.б.).*

**КИМ ҖӨМЛӘ –** җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган барлык кисәге дә кулланылмаган төре. Ул кисәк контексттан, обстановка, кул һәм йөз хәрәкәтләреннән аңлашыла. К.җ. җанлы сөйләмдә, диалогларда күп кулланыла. Мәсәлән,

— *Син бүген сәгать ничәдә кайтасың?*

— *Сигездә.*

— *Ә.Еникинең «Рәшә» повестен кем укыды?*

— *Мин. Чаг.*: **Тулы җөмлә.**

**КИРЕ СҮЗ ТӘРТИБЕ.** *Кара*: **Инверсия.**

**КИРЕ ХӘЛ –** хәл иярчен кисәгенең процессның киресе булачагын белдерә торган төркемчәсе. Ияртүче сүзгә шарт фигыль, *-ып/-еп/-п* формалы хәл фигыль һәм урын-вакыт килешендәге үткән заман сыйфат фигыль формаларына *да/дә, та/тә* кисәкчәләре ялганып яки *карамастан* бәйлек сүзе ярдәмендә иярә. Мәсәлән, *күрсә дә әйтмәү, белеп тә дәшмәү, ишеткәндә дә хәбәр итмәү, яңгырга карамастан килү.*

**КОММУНИКАТИВ СИНТАКСИС –** (лат. *communicatio* < *communico* – гомумиләштерәм, бәйлим, аралашам; гр. *syntaxic* – төзелеш) – синтаксисның

аралашу процессында җөмләнең ролен билгеләү, актуаль кисәкләрне тикшерү белән шөгыльләнә торган юнәлеше.

**КОНКРЕТИЗАТОР.** *Кара*: **Ачыклагыч.**

**КОНТРАСТИВ СИНТАКСИС** (фр. *contraste*, гр. *syntaxic* – төзелеш) – төрле типтагы телләрнең синтаксик төзелешен чагыштырып өйрәнә торган юнәлеш.

**КУШМА ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), ике яки аннан артык хәбәрлеге булган төзелмә (*Кара*: **Хәбәрлек**). Ике хәбәрлеге булган җөмлә түбәндәгечә төркемләнә: тезмә кушма җөмлә һәм иярченле кушма җөмлә. Икедән артык хәбәрлеге булган җөмлә катлаулы кушма җөмлә дип атала.

**КУШТЫРНАКЛАР** – текстта туры сөйләмне; цитаталарны; әсәр, газета, журнал, завод-фабрика һ.б. атамаларын белдерүче ялгызлык исемнәрен; туры мәгънәсендә килмәгән сүзне аерып кую өчен кулланыла торган тыныш билгесе. Мәсәлән, *«Хәят» повесте, «Мәдәни җомга» газетасы, «Идел» журналы; Г.Тукай: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», — дип язган; Экологик проблемалар безне табигатебездәге бу «гүзәллекләр»гә борчылып, чаң сугарга мәҗбүр итә.*

**КҮЗАЛЛАУЛЫ (ТЕМАТИК) БАШ КИЛЕШ** – баш килештәге бер сүзнең, мәгънәсенә аерым басым ясау өчен, җөмлә алдына чыгарылуы нигезендә барлыкка килә торган форма. Нигез җөмләдә ул III зат күрсәтү, зат алмашлыклары яки III зат тартым кушымчалы исем белән алыштырыла һәм аның турында күбрәк мәгълүмат бирелә. Бу төр җөмләләр матур әдәбиятта һәм публицистикада күп кулланыла. Мәсәлән, *Татарстан! Нинди матур ил ул* (Ә.Исхак). *Каен! Исе ап-ачык булып борынны ярып керде* (А.Гыйләҗев).

**КҮЛӘМ ХӘЛЕ** – хәл иярчен кисәгенең процесс яки билгенең күләмен, дәрәҗәсен белдерә торган төркемчәсе. Ияртүче сүзгә бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр *(кадәр, хәтле, чаклы, тикле, саен; мәртәбә, тапкыр, кат һ.б.)*, хәл фигыль формалары, рәвеш ясагыч кушымчалар *(-дай/-дәй, -ча/-чә)* ярдәмендә бәйләнә; күләм-чама рәвешләре, сан һәм вакыт, үлчәм белдерә торган сүзләр белән белдерелә. Мәсәлән, *күп сөйләү, озак тору, өч чакрым үтү, ике сәгать утыру, илле сум түләү, рәсемдәге төсле матур, аккошлардай ак, төнгә чаклы калу, җиде кат уйлау.*

**КҮП ИЯРЧЕНЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ** – катлаулы кушма җөмләнең бер төре, бер баш җөмләгә берничә иярчен җөмләнең бәйләнеп килүе нигезендә барлыкка килә торган җөмлә. Төзелеше ягыннан 4 төргә бүленә: 1) тиңдәш иярүле, ягъни бер баш җөмләгә бер үк функцияне үтәүче иярчен җөмләләр бәйләнә. Мәсәлән, *Буе талчыбыктай, үзе уңган, шуның белән ул матурлар арасында да үзен кимсетергә юл бирмәде* (Г.Ибраһимов); 2) тиңдәш түгел ияруле, ягъни бер баш җөмләгә төрле функция үтәүче иярчен җөмләләр бәйләнә. Мәсәлән, *Мәхәббәт туса, чәчәк бөресе ачылгандай, бары үзеннән-үзе һәм үз вакыты белән генә туа ала ул* (Ә.Еники); 3) бер-бер артлы (дәрәҗә белән) ияруле, ягъни бер баш җөмләгә берничә җөмлә берсе артыннан берсе ияреп килә. Мәсәлән, *Сугыш бетеп, бер ел узгач, кайтты ул минем кара егетем, минем Бәхетгәрәем!* (Ә.Еники); 4) берничә төр ияруле, ягъни алда саналган ияру төрләренең икесе яки өчесе дә бергә кулланыла. Мәсәлән, *Күреп торасыз: фуражы бар хуҗалыклар салам юктан интегә* (Х.Хәйруллин).

**КҮПНОКТА (…)** – сөйләмнең әйтелеп бетмәвен яки текстның бер өлеше төшереп калдырылуын күрсәтү өчен кулланыла торган тыныш билгесе. Шулай ук икенче тема яки күренешкә кисәк кереп киткән очракта да кызыл юлдан башланган текст алдына күпнокта куела. Мәсәлән, *Дүрт аяклы ат та сөртенә. Сөртенмиме соң… Ничек кенә сөртенде әле!*

*... Атна-ун көннән уракка төшәбез дип йөргәндә, авылда бик тә сәер хәбәр таралды* (Р.Төхфәтуллин).

**КҮП ТЕЗМӘЛЕ КАТЛАУЛЫ КУШМА ҖӨМЛӘ –** катлаулы кушма җөмләнең бер төре, икедән артык җөмләнең үзара тезү юлы белән бәйләнүе нигезендә барлыкка килә. Аерым җөмләләр тезү (санау) интонациясе, тезүче теркәгечләр аша бәйләнешкә керә (*Кара*: **Тезүле бәйләнеш**). Мәсәлән, *Көне-төне кар ява, җил ыжгыра, туктаусыз буран уйный* (Г.Ибраһимов). *Төшендә Хәлимне әнисе чакыра, ә Хәлим аннан кача, ләкин аны тотып китерәләр* (И.Гази).

**КЫЕК СӨЙЛӘМ –** үзгәртелеп кулланылган чит сөйләм. Туры сөйләмне К.с.гә әйләндергәндә, баш кисәкләрдә төрле үзгәрешләр була, җөмләгә аерым сүзләр өстәлә: 1) хикәя җөмлә формасындагы туры сөйләмне К.с.гә үзгәрткәндә, ия иялек килешендәге тәмамлыкка әйләнә; хәбәр, исемләшеп, төшем килешен ала һәм аңа әйтте (хәбәр итте, белдерде) сүзе өстәлә. Мәсәлән, *Галия: "Мин дәрестән киләм", – диде. Галия үзенең дәрестән килүен әйтте***.** 2) Сорау җөмлә формасындагы туры сөйләмне К.с.гә әйләндергәндә, ия яки эндәш сүз, иялек (чыгыш) килешен алып, тәмамлыкка әйләнә; хәбәр, исемләшеп, төшем килешенә куела яисә, исемләшеп, турында (хакында) бәйлеге белән килә. Мәсәлән, *Акрын гына: "Сез көтәсезме?" – дип сорады* (Ә.Еники). *Акрын гына минем көтү-көтмәвемне сорады***.** 3) боерык җөмлә булган туры сөйләмне К.с.гә әйләндергәндә, ия юнәлеш килешендәге тәмамлыкка әйләнә; хәбәр инфинитив формасын алып, аңа кушты, боерды, үтенде кебек сүзләр өстәлә. Мәсәлән, *Әлфия: «Сез минем янга кереп чыгыгыз әле!» – диде. Әлфия безгә үзе янына кереп чыгарга кушты***.**

**КЫЕК ТӘМАМЛЫК.** *Кара*: **Тәмамлык.**

**КЫЗЫЛ ЮЛ** – текстның һәм аның аерым тема, күренеш һәм мәсьәләгә караган өзегенең (*Кара*: **Абзац**) беренче юлы.

**М**

**МАКРОТЕКСТ** (гр. *macros* – озын, зур; лат. *textum* – тукыма, кушылма, бәйләнеш). *Кара*: **Текст.**

**МАКСАТ ХӘЛЕ** – хәл иярчен кисәгенең процессның үтәлү-үтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерә торган төркемчәсе. Ияртүче сүзгә юнәлеш килеше кушымчасы, инфинитив формасы, *өчен* бәйлеге һәм *дип* бәйлек сүзе аша бәйләнә. Мәсәлән, *гөмбәгә бару, (сөт) сатарга йөрү, аңлатыр өчен тырышу, бәйрәмгә дип әзерләнү*.

**МИКРОТЕКСТ** (гр. *mikros* – кечкенә; лат. *textum* – тукыма, кушылма, бәйләнеш). *Кара*: **Текст.**

**МОДАЛЬ КИСӘКЛӘР** – җөмләдә сөйләүченең чынбарлыкка һәм сөйләмгә мөнәсәбәтен белдерүче кисәкләр. М.к.гә кереш сүзләр һәм эндәш сүзләр керә. *Кара:* **Кереш сүз. Эндәш сүз.**

**МОДАЛЬЛЕК** (фр. *modalite* < лат. *modus* – чара, ысул) – җөмләнең төп билгесе, сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерүе нигезендә барлыкка килә. Күп төрле модаль мәгънәләр (шатлану, үкенү, боеру, үтенү, кайгыру, ният, карар итү, мөмкинлек, теләк һ.б.) фигыль төркемчәләре кушымчаларында яки аларга нигезләнеп ясалган формаларда чагылыш таба. Шулай ук фигыльдә – зат, исемдә – тартым кушымчалары, зат алмашлыклары, эндәш сүзләр, ымлыклар, кереш сүзләр һ.б. да М.не белдерүдә катнашалар. Мәсәлән, *Соңга калма! Әйтә күр! Җырлагызчы! Дөнья буйлап сәяхәт итәсе иде! Алманча укый алам. Ул Төркиягә барасы итте. Әлбәттә, кеше кешесез яши алмый* (Ә.Еники).

*Чыкчы, и фикрем кояшы!* (Г.Тукай) *Ахрысы, бу эшне ул да яратыр кебек* (М.Мәһдиев).

**МОНОЛОГ** (гр. *monos* – бер, *logos* – сөйләм) – туры сөйләмнең бер төре; персонажның үз-үзенә, башка берәүгә яки халыкка мөрәҗәгать ителгән сөйләме.

**МӨНӘСӘБӘТЛЕ СҮЗ** – аналитик бәйләүче чара (*Кара*: **Аналитик чара**). М.с. булып күрсәтү, билгеләү алмашлыклары һәм аларга нигезләнеп ясалган күп төрле формалар (*шул, шунысы, шунда, шул вакытта, шунлыктан, шул сәбәпле, шуңа карамастан, монысы, моның өчен, барысы, бөтенесе, һәммәсе* һ.б.) һәм кечкенәрәк саннар килергә мөмкин. М.с. һәрвакыт баш җөмлә составында килә, иярчен җөмләне алыштыру сәләтенә ия, иярчен җөмләнең функциясен билгели. Мәсәлән, *Бәхеткә шунысы бар тагын: һәркем үз учагын үзенчә яга* (Ә.Гаффар). *Бөтен сер шунда: даһилыкка иң туры юл халык йөрәге аша уза* (Ә.Баян). Татар тел белемендә шулай ук ялгызак М.с.ләр һәм парлы М.с.ләрне дә аеру бар. Парлы М.с.ләр дип баш җөмләдә күрсәтү, билгеләү алмашлыклары яки кечкенәрәк саннарның килүе, ә иярчен җөмләдә сорау алмашлыкларының урын алуы атала. *Кара*: **Теркәгеч сүз.** Мәсәлән, *Кем аерылмый, шулар белми аерылу сагышларын* (җыр).

### Н

**НОКТА (.)** – хикәя җөмлә һәм тыныч тавыш белән әйтелгән боерык җөмлә ахырында, драма әсәрләрендә персонаж исеменнән соң куела торган тыныш билгесе. Н. шулай ук инициаллар һәм шартлы кыскартылмаларда да кулланыла. Мәсәлән, *М.З.Зәкиев, Ф.С.Сафиуллина; һ.б. (һәм башкалар), һ.ш.о. (һәм шуңа охшашлар), б.э.к. (безнең эрага кадәр).*

**НОКТАЛЫ ӨТЕР (;)** – теркәгечсез бәйләнеп килгән тиңдәш кисәкләр һәм күп тезмәле катлаулы кушма җөмләләр җәенке булып, үз эчләрендә тагын тыныш билгеләре булган очракта куела торган тыныш билгесе. Мәсәлән, *Әйдә халыкка хезмәткә, Хезмәт эчендә йөзмәккә; Бу юлда һәртөрле хурлыкка, Зорлыкларга түзмәккә!* (Г.Тукай)

## О

**ОБЪЕКТ** (лат. *objektum* – предмет) – семантик синтаксисның өйрәнү объекты. Традицион (грамматик) синтаксиста тәмамлыкка туры килә. Фигыль белән белдерелгән эш-хәрәкәт юнәлдерелгән предмет яки затны белдерә. Синтаксик функциясе буенча субъектка каршы куела. *Кара*: **Семантик кисәкләр.**

**ОБЪЕКТ МӨНӘСӘБӘТЕ** – сүзтезмәдә ияртүче сүз тарафыннан ияртүченең объекты белдерелү нигезендә барлыкка килә торган мөнәсәбәт. Мәсәлән, *әнисенә бирү, китап уку, каләм белән язу, дусты турында сөйләү.*

## Ө

**ӨНДӘҮ БИЛГЕСЕ (!)** – тойгылы хикәя һәм тойгылы боерык (өндәү) җөмләләр ахырында куела торган тыныш билгесе. Мәсәлән, *Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз, яз!* (Г.Тукай) *Нинди матурлык! Бер ел – безнең хыялыбыз алдында нинди кыска, нинди көчсез ул!..* (Ә.Еники)

**ӨСТӘЛМӘ** – төп җөмлә артыннан килеп, аның турында өстәмә фикер белдергән һәм аерым җөмлә итеп формалаштырылган сүз яки сүзтезмә. Язучы Ө.ләрне аларның мәгънәсенә игътибарны тагын да ныграк юнәлтү өчен куллана. Мәсәлән, *Куштирәк – бәләкәй авыл. Бер генә урамлы* (Н.Фәттах). *Минем дә яшисем килә. Кеше төсле!* (Г.Әпсәләмов) *Эх, минә хәзер киң*

*канатлы бөркет буласы иде дә, югарыга күтәреләсе иде. Канатларны киң җәеп* (Г.Гобәй).

**ӨТЕР (,)** – аерым сүз, сүзләр тезмәсен яки кушма җөмлә составындагы гади җөмләләрне бер-берсеннән аеру өчен хезмәт итүче тыныш билгесе.

## П

**ПАРАТАКСИС** (гр. *parataxis* – янәшә урнашу). *Кара*: **Тезүле бәйләнеш.**

**ПАРЦЕЛЛЯЦИЯ** (фр. *parcelle* – кисәк, өлеш) – синтаксик яктан бәйләнгән текстны интонация ярдәмендә аерымланган кисәкләргә (җөмләләргә) таркату. Мәсәлән, *Чаба-йөгерә. Казый. Ташый. Йөгерә-чаба. Ята. Ашый...* (Р.Фәйзуллин) *Шигырьдән түгел, поэмалардан башлап китте Әхсән Баян. Ун ел элек, 1959-60 елларда. Ике буын уртасында... Ш.Галиев белән Р.Фәйзуллиннар буыны уртасында...* (С.Хәким)

**ПОЛИЛОГ** (гр. *polys* – күп санлы, *logos* – сөйләшү) – туры сөйләмнең бер төре, күп кешеләрнең берьюлы сөйләве нигезендә барлыкка килә. Мәсәлән,

*Халык шау килде:*

- *Тизрәк җыенып бетәргә кирәк! Үзебезнең мөселман мәмләкәтенә китәбез!*

- *Җитәр, патша-түрәләрнең җәбер-золымына күп түздек!*

- *Яңа җирдә тормышыбыз тыныч, тамагыбыз тук булыр, ичмасам* (М.Галәү).

**ПРАГМАТИК СИНТАКСИС** (гр. *pragma* – эш, гамәл; *syntaxic* – төзелеш) – синтаксисның бер юнәлеше, фикерне тыңлаучыга җиткерүче чараларны, чынбарлыкның фикердә чагылу дәрәҗәсен тикшерү белән шөгыльләнә.

**ПРЕДИКАТ** (лат. *praedicatum* – әйтелгән) – 1. Семантик синтаксисның өйрәнү объекты, сөйләмнең мәгънәви төзелешендәге төп компонент. П. сөйләм чикләрендә чынбарлыктагы яки уйлап чыгарылган хәлләрне тасвирлый (*Кара*: **Семантик кисәкләр. Хәбәр итү**). 2. Логик фикерләүнең бер кисәге (субъект – предикат). 3. *Кара*: **Хәбәр.**

**ПРЕДИКАТИВЛЫК.** *Кара*: **Хәбәр итү.**

**ПРЕДИКАТИВ НИГЕЗ.** *Кара*: **Хәбәрлек**.

## Р

**РАСЛАУ ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең чынбарлыктагы күренешләрне раслап әйтүгә нигезләнеп төзелгән төре. Татар телендә раслау җөмләнең махсус күрсәткече юк. Мәсәлән, *Ул килде. Уйнаган көннәрем бар, уйланган көннәрем бар* (Р.Гәрәй). Сөйләм телендә раслау мәгънәсе инкарь күрсәткечләре белән дә белдерелергә мөмкин. Мәсәлән, *Бармады ди! Бармаска! Бармас сиңа! Нинди бармау! Бармас инде! Бармый ни! Бармаган кая! Бармас! һ.б. Чаг.*: **Инкарь җөмлә.**

**РӘВЕШ ХӘЛЕ** – хәл иярчен кисәгенең процессның үтәлү рәвешен яки билгенең билгесен белдерә торган төркемчәсе. Ияртүче сүзгә чыгыш килеше кушымчасы, хәл фигыль формалары, рәвеш ясагыч кушымчалар (*-ча/-чә, -дай/-дәй*), бәйлек һәм бәйлек сүзләр (*кебек, шикелле, төсле, сыман, күк, рәвештә, формада, булып, килеш, буенча һ.б.)* ярдәмендә һәм янәшә торып буйсына. Мәсәлән, *эшләпәдән йөрү, яратып карау, искечә уйлау, йолдызлар булып кабыну, су кебек кирәк, яхшы күрү, кызу йөрү.*

**РЕЛЯТИВ МӨНӘСӘБӘТ** (лат. *relativus* – чагыштырмалы) – сүзтезмәләрдә ияручe сүз тарафыннан фигыль белән белдерелгән иярткүченең төрле билгеләре ачыклану нигезендә барлыкка килә торган мөнәсәбәт. Мәсәлән, *бүген сөйләү, яхшы уку, тиз арада башкару, әйткәнче уйлау.*

**РЕМА** (гр. *rhema* – сүз, әйтелмә; әйтелгән) **(СӨЙЛӘМ ЯҢАЛЫГЫ) –** җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленешендә сөйләм предметы – тема хакында яңа мәгълүмат алып килүче һәм сөйләмнең коммуникатив үзәген тәшкил итүче өлеше. *Кара*: **Актуаль кисәкләр.**

**РЕПЛИКА** (фр. *replique*) – диалог яки полилогта катнашучыларның һәр аерым әйтелмәсе. Һәрбер реплика кызыл юлдан языла. Әдәби әсәрләрдә аның алдына сызык куела. Драма әсәрләрендә персонаж исеменнән соң бирелә. Мәсәлән,

— *Әти, нинди кош икән ул, ә?*

— *Белмим, улым…*

— *Сандугач ул, әйеме, әти?* (Ф.Яруллин)

*Ана. Утыр! Утыр, улым, утыр!..*

*Инсаф. Менә, әни! Син чәчәк яратасың бит, чәчәк алып килдем әле сиңа…* (Ш.Хөсәенов)

**РЕФЕРЕНТ** (лат. *referens (referentis)* – чагыштыручы, мөнәсәбәт белдерүче) – чынбарлыкның, ягъни кеше аңыннан тыш реаль яши торган күренешләрнең, сөйләүче яки язучы тасвирлаган (күздә тоткан) объекты. Шулай ук чынбарлыкның үзен дә Р. термины белән атау күзәтелә.

**РЕФЕРЕНЦИЯ** – сөйләм семантикасының чынбарлыкка мөнәсәбәте. Икенче төрле репрезентация дип тә атыйлар.

## С

**СӘБӘП ХӘЛЕ** – хәл иярчен кисәгенең процессның үтәлү-үтәлмәү яки билгенең булу-булмау сәбәбен белдерә торган төркемчәсе. Ияртүче сүзгә юнәлеш һәм чыгыш килеше кушымчалары, бәйлекләр яки бәйлек сүзләр (*сәбәпле, аркасында, күрә, өчен*), хәл фигыль формалары (*-гач/-гәч, -ып/-еп/-п*) аша бәйләнә. Мәсәлән, *тавышка уяну, шатлыктан елау, авыру сәбәпле килмәү, күрмәгәч сөйләшә алмау.*

**СЕМАНТИК КИСӘКЛӘР** – семантик синтаксисның төп өйрәнү объектлары. С.к.гә субъект, предикат, объект, атрибут һәм ачыклагыч (квалификатор, конкретизатор) керә. Татар тел белемендә аларны түбәндәге шартлы билгеләр белән күрсәтәләр: Пре. – предикат (хәр.Пре. – хәрәкәт предикаты, йөр.Пре. – йөрү предикаты, аңл.Пре. – аңлату-сөйләү предикаты һ.б.), Суб. – субъект (сиз.Суб. – сизү субъекты, аңл.Суб. – аңлату субъекты һ.б.), Об. – объект, Ат. – атрибут һәм Ач. – ачыклагыч. Мәсәлән, *Илһам иртә белән мәктәпкә китте: йөр.Суб. – вак.Ач. – юн.Ач. – йөр.Пре.*

**СЕМАНТИК СИНТАКСИС** (гр. *semantikos* – белдерә торган, *syntaxic* – төзелеш) – синтаксисның сөйләм төзелешен мәгънәви яктан гына өйрәнүне нигез итеп алган юнәлеше. Семантик кисәкләрне тикшерү белән шөгыльләнә.

**СЕМИОТИК СИНТАКСИС** (гр. *semeiotike* < *semeion* – билге, *syntaxic* – төзелеш) – синтаксисның сөйләмне һәм аның берәмлекләрен өч яклап: синтактикасын (формасын), семантикасын (мәгънәсен) һәм прагматикасын (яшәү максатын) өйрәнә торган юнәлеше.

**СИНТАГМА** (гр. *syntagma* – бергә төзелгән, бәйләнгән) – синтаксик берәмлекләрнең берсе, бер яки берничә сүзнең билгеле бер интонация белән

әйтелгән мәгънәле кисәге. Мәсәлән, *И туган тел / и матур тел / әткәм-әнкәмнең теле* (Г.Тукай).

**СИНТАКСИК БӨТЕН.** *Кара*: **Текст.**

**СИНТАКСИС** (гр. *syntaxic* – төзелеш) **–** тел белеменең сөйләм төзелешен өйрәнә торган тармагы. Синтаксисның төп берәмлекләре: сүзтезмә, җөмлә (гади җөмлә, кушма җөмлә), синтагма, текст.

**СИНТЕТИК ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ** – иярченле кушма җөмләдә баш җөмләгә синтетик чаралар ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмлә. Бу төр җөмлә тәмамланмаган төсмер ала: ия белән хәбәр затта ярашмый. Иярчен җөмлә үзеннән соң баш җөмләнең килүен таләп итә. С.и.җ. төрки телләрнең үзенчәлеге булып санала. Мәсәлән, *Кунаклар килеп җиту белән*, *бәйрәм башланды. Кояш чыккач*, *көн җылынды. Чаг.*: **Аналитик иярчен җөмлә.**

**СИНТЕТИК ЧАРА** – синтетик иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртүче чара. С.ч.ларга килеш кушымчалары, рәвеш һәм сыйфат ясагыч кушымчалар (*лы/-ле, -сыз/-сез, -ча/-чә, -дай/-дәй, -лык/-лек* һ.б.), фигыль формалары, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору керә. С.ч.лар иярчен җөмләнең хәбәре составында килә, шуңа күрә хәбәр тулы формада булмый. *Чаг.*: **Аналитик чара.**

**СОРАУ БИЛГЕСЕ (?)** – сорау җөмлә ахырында куела торган тыныш билгесе. Мәсәлән, *Ул киләчәкме? Син бәхетлеме, синең гүзәллегең һәм акылыңның кадерен беләләрме бу дөньяда?* (М.Мәһдиев)

**СОРАУ ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең әйтү максаты ягыннан аерылган төре, нәрсәне дә булса белү, раслау омтылышы һәм теләге

белән әйтелгән җөмлә. С.җ.гә сорау интонациясе, сорау алмашлыклары һәм кисәкчәләре хас. Мәсәлән, *Кем ул? Кайдан килгән? Сез язучымы? Аның Г.Хәсәнов хикәяләрен укыганы бармы икән? Чаг.*: **Хикәя җөмлә. Боерык җөмлә.**

**СТРУКТУР КИСӘКЛӘР –** структур синтаксисның төп өйрәнү объекты. С.к. морфологик категорияләр нигезендә билгеләнә. Структур анализ шартлы билгеләр ярдәмендә ясала. Мәсәлән, *И. – исем, С. – сыйфат, т.Сан – тәртип саны, к.А. – күрсәтү алмашлыгы, х.Р. – хәл рәвеше, Ф.-у -исем фигыль һ.б.* Бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәре, ярдәмче фигыльләр, күпчелек кушымчалар, фигыль формалары тулы килеш языла. Мәсәлән, *Ул бүген төсле карандашлар белән бик матур рәсем ясады: з.А – х.Р. – С. – И.-лар белән – б.Р. – С. – И. – Ф.-ды.*

**СТРУКТУР СИНТАКСИС** (лат. *structura* – төзелмә, корылма; гр. *syntaxic* – төзелеш) – синтаксисның бер юнәлеше, сөйләм төзелешенең форма ягын гына тикшерүгә өстенлек бирә, өйрәнү объекты итеп структур кисәкләрне ала. Сөйләм структурасының эчке закончалыкларын ачканда, еш кына җөмлә төзелешен үзгәртеп карау юлы белән эш иткәнлектән, аны трансформацион синтаксис дип тә атыйлар, генератив дигән атама да кулланалар.

**СУБЪЕКТ** (лат. *subjectum* – кеше, зат) – семантик синтаксисның өйрәнү объекты, җөмләдәге сөйләм предметын белдерә. *Кара*: **Семантик кисәкләр.** Грамматик С., җөмлә кисәкләре турындагы өйрәтмә буенча, ия белән тәңгәл килә. Синтаксик-семантик теориядә агенс булып карала һәм объектка каршы куела. Логик С. – җөмләдә фикерләүнең субъектына туры килүче һәм предикатка каршы куелучы кисәк.

**СҮЗ ҖӨМЛӘ –** бер составлы гади җөмләнең җөмлә кисәкләренә аерып булмый торган төре. С.җ. ымлыклар, аваз ияртемнәре, хәбәрлек сүзләр, кайбер

кисәкчәләр белән бирелә, сөйләүченең сөйләмгә һәм чынбарлыкка төрле мөнәсәбәтен белдерә. Мәсәлән, *Әйе. Ярар. Дөрес. Түгел. Инде... Соң? Ух! Ура! Тсс! Их!*

**СҮЗЛӘР БӘЙЛӘНЕШЕ** – синтаксисның өйрәнү предметы – сөйләм төзелешенең төп нигезен тәшкил иткән бәйләнеш. Сүзләр бәйләнеше ике төрле булырга мөмкин: тезүле бәйләнеш һәм ияртүле бәйләнеш.

**СҮЗЛӘРНЕҢ КИРЕ ТӘРТИБЕ.** *Кара*: **Инверсия.**

**СҮЗЛӘРНЕҢ ТУРЫ (УҢАЙ) ТӘРТИБЕ** – җөмләдә сүз тәртибенең күбрәк язма сөйләмдә, әдәби телдә кулланыла торган төре. Татар телендә туры тәртиптәге сүзләр түбәндәгечә урнашалар: ия хәбәрдән алда килә, хәбәр җөмләне тәмамлый; ачыклаулы (төгәлләүле) мөнәсәбәттәге сүзләрнең ияручесе иярткечедән алда урнаша, ягъни аергыч аерылмыштан, тәмамлык һәм хәлләр үзләре ияргән сүздән алда куела; аныклагыч аныкланмыштан соң килә. Мәсәлән, *Без, Идел буе халыклары, борын-борын заманнардан бирле күп милләтле, зур һәм тату гаилә булып яшибез* (Г.Бәширов). Сүзләрнең урнашу тәртибе җөмләнең актуаль кисәкләре белән дә бәйле. *Кара*: **Актуаль кисәкләр**. *Чаг.*: **Инверсия.**

**СҮЗТЕЗМӘ** – мөстәкыйль мәгънәле кимендә ике сүзнең ачыклаулы мөнәсәбәткә керүе нигезендә барлыкка килгән синтаксик берәмлек. Сүзтезмәләрнең түбәндәге төрләре аерыла: ирекле (синтаксик) С. (*өй ачкычы, таш күпер*) һәм тотрыклы (фразеологик) С. (*тел ачкычы, таш күңел*); гади С. (*ел саен очрашу, озак сөйләшү*) һәм катлаулы С. (*узган ел очрашу, бер сәгать сөйләшү*). Ияруче һәм иярүче сүзләрнең нинди сүз төркеме белән белдерелүенә карап, күп санлы төрләр билгеләнә. Мәсәлән, *җылы яңгыр* – сыйфатлы исем С., *киләсе көн* – фигыльле исем С., *бүген матур* – рәвешле сыйфат С., *бишкә бүлү* – санлы фигыль С., *юк-бар йомыш* – хәбәрлек сүзле

исем С. Сүзтезмә компонентлары арасында атрибутив, релятив һәм объект мөнәсәбәтләре урнашырга мөмкин.

**СЫЗЫК (–)** – гади һәм кушма җөмләдә кулланылучы һәм күп төрле мәгънәви-синтаксик функцияләр үтәүче тыныш билгесе. Сызык түбәндәге очракларда куела: ия белән хәбәр исем яки исемләшкән сүз төркемнәре, исем фигыль, сан белән белдерелгәндә *(Китап – гомерлек юлдаш* (мәкаль). *Уку – сукырга таяк тоттыру* (мәкаль). *Җиде бишең – утыз биш. Ә яшьлек ул – юл дигән сүз, очсыз-кырыйсыз юл* (Г.Әпсәләмов)*)*; исем белән белдерелгән һәм мәгънә күләмнәре бердәй булган аныклагыч һәм аныкланмыш арасында *(Якташларым – аппаккыналарым – ак каеннар тора каршымда* (Х.Туфан)*)*; тиңдәшләнеп килгән аныклагычларны ике яктан аеру өчен *(Без – руслар, украиннар, татарлар, белоруслар – корыч стена булып, сине якларга киттек* (Г.Кутуй)*)*; ким җөмләләрдә кулланылмаган кисәк урынына *(Мин иртүк мәктәпкә китәм, ә әнием – эшкә)*; җөмләне ике төрле аңлау куркынычы булганда *(Теге – агач йорт янында тора)*; кискен каршы кую интонациясе аша бәйләнгән тиңдәш кисәкләр *(Кояш чыга – җылытмый)* яки теркәгечсез тезмә кушма җөмлә компонентлары арасында *(Хезмәтнең тире ачы – җимеше татлы* (мәкаль)*)*; тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан *(Аның җиңсез ак күлмәге, кояшта каралган беләк-балтырлары, аркасыннан салынып төшкән чәч толымы – һәммәсе дә ишектә югалды* (Ф.Садриев)*)*; теземдә төп бүлектән алда килгән санау бүлегеннән соң (*Кара*: **Тезем**); туры сөйләмдә *(Сания: «Мин бүген концертка барам», – дип әйтте)* һәм әдәби әсәрләрдәге репликалар алдыннан.

**СЫЗЫКЧА (ДЕФИС)** – парлы яки кабатлаулы сүзләрне язу өчен, шулай ук сүзләрне юлдан-юлга күчергәндә кулланыла торган тыныш билгесе. Мәсәлән, *көньяк-көнбатыш, кызыллы-яшелле, алпан-тилпән, яна-көя; җырлый-җырлый, кызу-кызу, чиләк-чиләк; кып-кызыл, ямь-яшел.*

## Т

**ТАКСИС** (гр. *taxis* – төзелеш, тәртип, урнашу) – җөмлә яки текстның зуррак өлешендә хәбәр ителүче процесс белән вакыт арасындагы мөнәсәбәтне (эшнең бер үк вакытта, бер-бер артлы, дәвамлы, ара-тирә һ.б. үтәлүен) чагылдыручы мәгънәви категория. Татар телендә Т. морфологик яктан хәл фигыль формалары *(килгәч күрү, сөйләшеп утыру, озата бару, киткәнче сөйләшү)*, процессның үтәлү дәрәҗәсен белдерүче формалар *(көлеп җибәрү, егыла язу, биергә тотыну, укый башлау, явып тору, яшәп яту, елмаеп кую, әйтеп ташлау, сөйләп бетерү)*, сыйфат һәм исем фигыльләрнең төрле килешләрдә һәм бәйлек яки бәйлек сүзләр белән кулланылган формалары *(сөйләгәндә күрү, килүенә әзер булу, очрашканнан соң хәл итү, килгәненнән алып ял итү)* белән белдерелә.

**ТАРИХИ (ДИАХРОНИК) СИНТАКСИС** – тарихи грамматиканың бер тармагы; бер тел, конкрет телләр яки телләр төркеменең синтаксик төзелеше үсешендәге закончалыкларны өйрәнә.

**ТАСВИРИ (СИНХРОНИК) СИНТАКСИС** – аерым бер телнең билгеле бер үсеш этабындагы (күбесенчә хәзерге чордагы) синтаксик төзелешен өйрәнә торган юнәлеш.

**ТӘМАМЛЫК** – җөмләдә процесс белдерүче сүзне ачыклап, аның объектын яки үтәүчесен белдерә торган иярчен кисәк. Ике төре билгеләнә: туры Т. һәм кыек Т. Туры Т. процесс турыдан-туры кагылган предмет яки төшенчәне белдерә. Татар телендә туры Т. төшем килешендәге *(мәкаләне язу, аны күрү)*, билгесез килеш формасындагы *(китап уку, рәсем ясау)*, сирәк кенә чыгыш килешендәге *(кулыннан тоту, өчпочмактан авыз итү)* исем яки алмашлыклар белән белдерелә, көчемле фигыльләргә генә ияртә. Кайбер галимнәр инфинитив белән белдерелгән туры Т.ларны да аерып чыгаралар

*(китәргә уйлау, мактанырга ярату)*. Кыек Т. процесс турыдан-туры кагылмаган объект яки үтәүчене белдерә, ияртүче сүзгә юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше кушымчалары; *белән, өчен, турында, хакында, аша, аркылы, каршы, башка, тыш* һ.б. бәйлекләр ярдәмендә ияртә. Мәсәлән, *әнигә бүләк итү, аннан сорау, дусты өчен шатлану, тел аркылы белү, бәйрәм турында сөйләү*.

**ТЕЗЕМ** – текстның бер төре, тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу сәбәпле, бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмлә. Күбрәк поэзиядә кулланыла. Т.дә санау бүлеге һәм төп бүлек була. Әлеге бүлекләрнең ничек урнашуына карап, Т. өч төрле була: 1) төшмә Т.дә санау бүлеге алдан килә. Мәсәлән, ... *Каеннарның талгын шаулавы,*

*Зифа буйлы сылу камышлары,*
*Тургайларның дәртле җырлавы,*
*Кәккүкләрнең моңлы тавышлары,*
*Табигатьнең иркен сулавы –*
*Күз алдымнан китмәс һичбер вакыт,*
*Онытылмаслар гомерем буена* (С.Урайский).

2) күтәрелмә Т.дә төп бүлек алдан урнаша. Мәсәлән,

*Шуннан китте, и китте...*
*Мине чын солдат итте:*
*Бетте ялкау гадәтем,*
*Санаулы һәр сәгатем:*
*Иртүк торам, юынам,*
*Сөлге белән уынам,*
*Ялт иттерәм тешләрне,*
*Аннан эшлим эшләрне...* (Җ.Дәрзаманов)

3) катнаш Т.дә төп бүлек санау бүлеге эчендә берничә тапкыр кабатлана. Мәсәлән,

*Якын миңа: тымызык елгаларың,*

*Инешләрең, чишмә, күлләрең,*
*Чәчәк аткан алма бакчаларың,*
*Үрмәләнеп үскән гөлләрең;*
*Якын миңа: әвен, кибәннәрең,*
*Болыннарың, иркен кырларың,*
*Томан төшкән яшел үләннәрең*
*Һәм зәңгәрсу торган урманың* (С.Хәким).

**ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ** – аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмләне төзүче җөмләләр бер-берсенә буйсынмыйлар, үзара тигез хокуклы булалар, чагыштырмача мөстәкыйльлек саклыйлар. Т.к.җ. ике төргә бүленә: теркәгечле тезмә кушма җөмлә һәм теркәгечсез тезмә кушма **җөмлә.**

**ТЕЗҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ** – сүз яки җөмләләрнең бер-берсенә буйсынмавына, тигез хокуклы булуына нигезләнгән бәйләнеш. Т.б. тиңдәш кисәкләр арасында, тезмә кушма җөмлә һәм күп тезмәле катлаулы кушма җөмләләрдә була. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар: тезүче теркәгечләр *(һәм, вә, да/дә, та/тә, янә, тагын, ни-ни; ләкин, әмма, вәләкин, тик, бары, бары тик; я, яки, яисә, әле-әле, әллә-әллә һ.б.)*, тезү (санау) интонациясе һәм каршы кую интонациясе. *Чаг.*: **Ияртүле бәйләнеш.**

**ТЕКСТ** (лат. *textum* – тукыма, кушылма, бәйләнеш) – синтаксисның иң зур берәмлеге; өйрәнү өчен алынган, эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан оешкан тоташ сөйләм. Икенче төрле аны мәгънәви, тематик, композицион, логик, структур, грамматик бөтен дип атыйлар. Т.ның ике төре бар: макротекст (әсәр бүлекләре, кыскарак хикәя һәм нәсерләр, мәкаләләр; беркетмә, белешмә, гариза һ.б. эш кәгазьләре; закон, карар һ.б. рәсми документлар) һәм микротекст (аерым абзацлар, тезем, кечкенә шигырьләр һ.б.). Микротекстны синтаксик бөтен атамасы белән дә йөртәләр.

**ТЕМА** (гр. *thema)* **(СӨЙЛӘМ ПРЕДМЕТЫ)** – җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленешендә тыңлаучы (укучы) өчен алдагы җөмләдән яки башка чыганаклардан билгеле булган өлеше. *Кара*: **Актуаль кисәкләр.**

**ТЕРКӘГЕЧЛЕ ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ** – тезмә кушма җөмләнең аерым җөмләләре үзара тезүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән төре. Мәсәлән, *Болытлар таралдылар, һәм көн матурланды. Ни мин бармадым, ни үзе килмәде. Бераздан җыр тынды, ә мин һаман тынычлана алмадым* (А.Шамов). *Әле яңгыр ява, әле кояш кыздыра.* Т.т.к.җ. эчендәге гади җөмләләр бер-берсеннән өтер белән аерыла, бары *һәм* теркәгече ярдәмендә бәйләнгән төзелмәдә һәр ике гади җөмләгә дә караган уртак кисәк булган очракта гына *һәм* теркәгече алдына өтер куелмый. Мәсәлән, *Безнең Татарстанда татар теле дәүләт теле буларак кулланыла һәм башка телләр үсешенә дә мөмкинлекләр тудырыла* («Ватаным Татарстан»). *Чаг.*: **Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.**

**ТЕРКӘГЕЧСЕЗ ТЕЗМӘ КУШМА ҖӨМЛӘ** – тезмә кушма җөмләнең аерым җөмләләре үзара тезү (санау) яки каршы кую интонацияләре аша бәйләнгән төре. Т.т.к.җ. эчендәге гади җөмләләр бер-берсеннән өтер белән аерыла, кискен каршы кую интонациясе аша бәйләнгәннәре арасына исә сызык куела. Мәсәлән, *Көн матур, кояш үзенең ягымлы, рәхимле елмаюы белән тышка, урамга чакыра* (В.Касыймова). *Яшьлектә белгән ташка язган, картлыкта белгән бозга язган* (мәкаль). *Бер барды, ике барды – тегесе өйдә булмады* (Г.Ибраһимов). *Чаг.*: **Теркәгечле тезмә кушма җөмлә.**

**ТЕРКӘГЕЧ СҮЗ** – аналитик бәйләүче чара. Сорау алмашлыклары яки аларга нигезләнеп ясалган күп төрле формалар, иярчен җөмлә составында килеп, я үзләре генә, я мөнәсәбәтле сүз белән бергә, бәйләүче чара булып киләләр. Т.с. җөмлә кисәге функциясен үти, әмма аңа карап, иярчен җөмләнең

төрен билгеләп булмый. Мәсәлән, *Әйтегезче, мәтрүшкәләр, ни әйтергә әнкәм теләгән?* (И.Юзеев) *Кемнең итәгенә ут төшсә, шул яна* (мәкаль). Хәзерге татар синтаксисында Т.с.не парлы мөнәсәбәтле сүзләр составында тикшерәләр. *Кара:* **Мөнәсәбәтле сүз.**

**ТИҢДӘШ ИЯРҮЛЕ ҖӨМЛӘ.** *Кара:* **Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**

**ТИҢДӘШ ТҮГЕЛ ИЯРҮЛЕ ҖӨМЛӘ.** *Кара*: **Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**

**ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР** – бер үк синтаксик функцияне үтәп, бер җөмлә кисәгенә ияреп килүче, үзара тезүле бәйләнештә торучы сүзләр. Мәсәлән, *Ак, кызыл, ал чәчәкләргә бал корты куна* (Н.Баян). *Мин моны тиз генә эләктердем дә әнигә китердем* (Г.Ибраһимов).

**ТОЙГЫЛЫ ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең тойгы интонациясе белән әйтелгән төре. Т.ж.ләргә кире сүз тәртибе (инверсия), ымлыклар, сорау алмашлыклары, төрле кабатлаулар хас. Мәсәлән, *Бәхет дигәнең, һай, матур икән!* (Зөлфәт) *Рәхәт үз өеңдә, бик рәхәт...* (М.Мәһдиев) *Чаг.*: **Гадәти җөмлә.**

**ТӨГӘЛЛӘҮЛЕ МӨНӘСӘБӘТ.** *Кара*: **Ачыклаулы мөнәсәбәт.**

**ТУЛЫ ҖӨМЛӘ** – җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган барлык кисәкләре дә булган төре. Тулы җөмләләр бүлек, абзац башларында, яңа фикер башлап җибәргәндә күбрәк кулланылалар. Төрле

билгеләмәләр, кагыйдәләр, рәсми документлар (законнар, карарлар һ.б.) гадәттә тулы җөмләләр белән языла. *Чаг.*: **Ким җөмлә.**

**ТУРЫ СӨЙЛӘМ** – чит сөйләмнең бер төре, текст эченә килеп кергән башка кеше сүзләренең үзгәртелмичә кулланылуы нигезендә барлыкка килә. Т.с.нең диалог, полилог, монолог, цитата кебек төрләре бар. Т.с.не автор сөйләменә бәйләүчеләр булып әйтүгә һәм уйлауга кагылышлы фигыльләр йөри, аларның иң активлары – *дип, ди, дигән*. Т.с. куштырнаклар эченә алына; диалог яки полилог рәвешендә бирелсә, яңа юлдан сызык белән языла; драма әсәрләрендә персонаж исеменнән соң бирелә. Мәсәлән, *Берничә сәгатьтән соң аталары, балаларын янына чакырып: “Алмаларны ни эшләттегез?” – дип сорады.*

*Өлкән угылы әйтте:*

*– Әти! Мин алмамны ашадым. Эчендәге орлыкларын җыеп куйдым. Бакчабызга чәчеп алма агачы үстермәк буламын* (Дәрдемәнд).

**ТУРЫ ТӘМАМЛЫК.** *Кара*: **Тәмамлык.**

**ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ (ПУНКТУАЦИЯ)** – язуда кулланылучы һәм алфавитка кермәгән график билгеләр. Аларның төп максаты – язма текстны мәгънәви, интонацион, грамматик һәм коммуникатив кисәкләргә бүлү. Тыныш билгеләренә түбәндәгеләр керә: нокта, өтер, сорау билгесе, өндәү билгесе, сызык, ике нокта, күпнокта, нокталы өтер, җәяләр, куштырнаклар.

## У

**УРТАК СӨЙЛӘМ** – туры сөйләмнең бер төре, автор сөйләме белән персонаж сөйләменең кушылып китүе нигезендә барлыкка килә. Автор персонаж булып уйлый, фикер йөртә башлый. У.с. хикәяләүгә табигыйлек,

җанлылык алып керә, аның эмоциональ көчен, образлылыгын арттыра. Хәзерге матур әдәбиятта бик күп кулланыла. У.с. III зат исеменнән автор хикәяләве белән язылган әсәрләрдә күзәтелә, күпчелек очракта уйлады, уйланды, күз алдына китерде, искә төшерде кебек фигыльләрдән соң башланып китә. У.с.дә зат алышына, фигыль формалары үзгәрә, сүзләр кире тәртиптә урнаша, тойгылы җөмләләр кулланыла. Мәсәлән, *Ә Гөлзифаның йолдызы һаман яктырып-яктырып җемелди, каядыр өнди, каядыр чакыра. Кая өнди, кая чакыра икән ул? Нәрсәләр вәгъдә итә икән? Белсәң иде...* (Р.Төхфәтуллин) *Аннары ул икенче төрле уйлап бакты. ... Юк, болай булмый. Булмый! Алай итсә, Фәррахны да кинәт читен хәлгә калдырыр, үзенең дә нишләп бетәсен каян белә? Йә хәзер үк булмәсенә кереп күрешергә кирәк, йә инде иртәгә иртүк очратырга...* (Б.Камалов)

**УРЫН ХӘЛЕ** – хәл иярчен кисәгенең процесс яки билгенең үтәлү урынын белдерә торган төркемчәсе. Ияртүче сүзгә юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше кушымчалары, бәйлек һәм бәйлек сүзләр *(таба, белән, аша, аркылы, астында, өстендә, артында һ.б.)* ярдәмендә иярә. Мәсәлән, *мәктәптә булу, өйгә кайту, машинадан чыгу, күпер аша үтү, өстәл өстендә урын алу, юл буйлап килү).*

## Ү

**ҮТӘҮЧЕСЕЗ ҖӨМЛӘ** – бер составлы гади җөмләнең баш кисәге фигыль белән белдерелеп, үтәүчесен билгеләп булмый торган төре. Ү.ж. табигать күренешләрен яки кешенең эчке халәтен белдерү өчен кулланыла. Мәсәлән, *Суыта. Өрә. Туңдыра. Калтырата. Күзгә ак төште.*

## Ф

**ФУНКЦИОНАЛЬ СИНТАКСИС** (лат. *functio* – эшчәнлек, гр. *syntaxic* – төзелеш) – синтаксисның бер юнәлеше, аралашу процессында җөмлә үтәгән функцияләрне өйрәнү белән шөгыльләнә.

## Х

**ХӘБӘР** – җөмләнең ия турында хәбәр итә торган баш кисәге. Ия белән хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә бәйләнә. Татар телендә хәбәрләрнең түбәндәге төрләре аерыла: гади исем хәбәр *(Бу китап аныкы),* гади фигыль хәбәр *(Өйгә керде)*; тезмә исем хәбәр *(Кыз – тәмле телле),* тезмә фигыль хәбәр *(Ул кызга күз ташлады. Кыз аның карашына игътибар итмәде)*; кушма исем хәбәр *(Көн томанлы иде. Килүем синең өчен. Дөнья матур ул!)* һәм кушма фигыль хәбәр. Кушма фигыль хәбәрнең 4 төре билгеләнә: процессның үтәлү дәрәҗәсен белдерүче *(Апа көлеп җибәрде. Әкрен генә яңгыр сибәләп тора),* модаль мәгънә белдерүче *(Әниемнең сүзен тыңлыйсым калган! И, ул да тыңласа икән бу моңнарны!* (М.Рафиков), эзлекле яки параллель процессларны белдерүче *(Ләйлә игъланны күчереп язып алып менеп күрсәтте. Ул юл буе яңалыкларны сөйләп барды)* һәм хикәя фигыльнең аналитик заманнарын белдерүче *(Әби безгә әкиятләр сөйли торган иде. Концерт әле башланмаган иде).*

**ХӘБӘР ИТҮ (ПРЕДИКАТИВЛЫК)** – җөмләнең төп билгеләреннән берсе, сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен тел чаралары ярдәмендә белдерү. Хәбәр итүне белдерүче чараларга фигыльдә зат-сан кушымчалары, заман формалары һ.б. керә. *Кара*: **Хәбәрлекле мөнәсәбәт.**

**ХӘБӘРЛЕК (ПРЕДИКАТИВ НИГЕЗ)** – җөмләнең үзәген тәшкил итүче баш кисәкләр: ике составлы җөмләләрдә – ия һәм хәбәр, бер составлы

җөмләләрдә – я ия (атау җөмлә), я хәбәр (фигыль җөмләләр). Хәбәрлекнең санына карап, җөмләләр гади һәм кушма төрләргә бүленәләр.

**ХӘБӘРЛЕКЛЕ МӨНӘСӘБӘТ –** ияртүле бәйләнешкә нигезләнгән һәм җөмләнең баш кисәкләре арасында була торган мөнәсәбәт. Х.м. җирлегендә җөмлә барлыкка килә. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүдә түбәндәге чаралар катнаша: зат-сан кушымчалары (*Марат мәктәптә укый),* килеш кушымчалары (*Мин – Казаннан. Ул өйдә),* хәбәрлек кушымчалары *(Мин студентмын. Ул укучыдыр),* кайбер сүз ясагыч кушымчалар *(Аның сөйләшүе саф татарча. Китап минеке. Кофе баллы),* бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр *(Китап өстәл өстендә. Чәче ефәк кебек),* сүз тәртибе *(Чәчәк матур. Егет көчле),* хәбәр итү интонациясе *(Г.Ибраһимов – күренекле әдип)*.

**ХӘЛ –** процессның үтәлү вакытын, урынын, рәвешен, сәбәбен, максатын, шартын һ.б. билгеләрен белдерүче иярчен кисәк. Х. рәвеш, исем, сыйфат, сан, хәл фигыль кебек сүз төркемнәре белән белдерелә. Хәлнең түбәндәге мәгънәви төркемчәләре аерыла: урын хәле, вакыт хәле, рәвеш хәле, күләм хәле, сәбәп хәле, максат хәле, шарт хәле, кире хәл.

**ХИКӘЯ ҖӨМЛӘ –** җөмләләрне төркемләүнең бер принцибына нигезләнеп (*Кара*: **Җөмләләрне төркемләү**), гади җөмләнең әйтү максатына карап аерылган төре, нәрсәне дә булса белдерү яки кире кагу өчен әйтелгән гадәти җөмлә. Хикәя җөмләгә хикәяләү интонациясе, сүзләрнең туры (уңай) тәртибе хас. Мәсәлән, *2005 нче елда Казанның меңьеллыгы бәйрәм ителде. Чаг.*: **Сорау җөмлә. Боерык җөмлә.**

# Ц

**ЦЕЗУРА** (лат. *caesura* – кисү, кискәләү) – шигырь юлы эчендә шул шигырь үлчәме өчен мәҗбүри пауза, тыныш. Синтагма белән туры килмәскә дә мөмкин. Ц. булып, шигырь юлларының билгеле бер сандагы иҗекләргә бүленешенә бәйле рәвештә, ярдәмлек сүзләр дә килә ала. Мәсәлән,

*Кичер мине, // илем, // синең бөек //*

*Исмең белән // килеп // сугышка, //*

*Данлы үлем // белән // күмәлмәдем //*

*Бу тәнемне // соңгы // сулышта //* (М.Җәлил).

**ЦИТАТА** (лат. *citatum* < *citare* – чакыру, атау) – нәрсәне дә булса дәлилләү, нигезләү максаты белән, берәр төрле тексттан үзгәртелмичә китерелгән өзек, өземтә. Ц. куштырнаклар эченә алына. Мәсәлән, *Күренекле татар галиме Г.Алпаров: "Татар телендәге иярчен җөмлә дип йөртелгән фактлар – аерым җөмлә белән җөмлә кисәге арасында ике уртадарак торган күренешләр", – дип язган.* Ц. итеп бирелгән шигырьләр куштырнаклар эченә алынмый. Мәсәлән, *Әллә инде кыш уртасында туганга, ул кышны аеруча яраткан:*

*Ак чәчәкләр ява,*

*Дөнья матур,*

*Шундый матур булып тоела,*

*Күге зәңгәр, гүя йолдызлары*

*Ак кар булып җиргә коела...*

*Фатих Хөснинең "күбәләк-күбәләк кар яуса, Һади Такташ хәтергә төшә" диюе шагыйрьнең әнә шул сәер мәхәббәтенә ишарә ясый* (Н.Юзиев).

## Ч

**ЧАГЫШТЫРМАЛЫ-ТАРИХИ СИНТАКСИС –** бер типка караган (кардәш) телләрнең синтаксик төзелеше үсешендәге закончалыкларны чагыштырып өйрәнә торган юнәлеш.

**ЧИТ СӨЙЛӘМ –** текст эченә килеп кергән башка кеше сүзләре. Ч.с.нең өч төре бар: туры сөйләм, кыек сөйләм һәм уртак сөйләм.

**ЧИТ СӨЙЛӘМЛЕ ТЕКСТ –** автор сөйләме һәм чит сөйләмнән торган текст.

## Ш

**ШАРТ ХӘЛЕ –** хәл иярчен кисәгенең процессның үтәлү-үтәлмәү шартын белдерә торган төркемчәсе. Иярткүче сүзгә шарт фигыль формасы; *икән, исә* бәйлек сүзләре; *-мы/-ме* сорау кисәкчәле хикәя фигыль формасы ярдәмендә бәйләнә. Мәсәлән, *укыса белер; әйтәмме – эшлим; барам икән, алып кайтам.*

## Э

**ЭКСПРЕССИВ СИНТАКСИС** (лат. *expressus* – көчәйтелгән, тәэсирле; гр. *syntaxic* – төзелеш) – синтаксисның бер юнәлеше, сөйләмдә тойгыны белдерү юлларын өйрәнү белән шөгыльләнә.

**ЭНДӘШ СҮЗ –** җөмләнең сөйләм төбәлгән зат, предмет яки күренешне белдерә торган модаль кисәге. Мәсәлән, *Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә* (Г.Тукай). *Күбәләгем, түгәрәгем, асыл кошым, сандугачым, син бит күңелем кояшы* (җыр).

## Ю

**ЮЛ ХӘРЕФЕ (КЕЧКЕНӘ ХӘРЕФ)** – телнең орфография һәм пунктуация кагыйдәләренә нигезләнеп, баш хәрефтән языла торган сүзләрдән тыш башка барлык очракларда кулланыла торган нормаль зурлыктагы хәреф. *Чаг.*: **Баш хәреф.**

# ӘДӘБИЯТ

*Татар телендә*


Зәкиев М.З. Татар теле синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе. – Казан: Тат. китап нәшр., 1984. – 256 б.

Мирзаһитов Р.Х., Шәйхиева Г.М. Хәзерге татар әдәби теле. Пунктуация. – Казан: Ихлас, 2013. – 52 б.

Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 264 б.

Сәгъдиева Р.К. Хәзерге татар теле синтаксисы. Лекцияләрнең кыскача конспекты. – Казан: Казан ун-ты, эл., 2014. – 119 б.

Сәгъдиева Р.К., Мирзаһитов Р.Х. Татар теленнән тестлар һәм мөстәкыйль эш биремнәре. Синтаксис. – Казан: Ихлас, 2014. – 60 б.

Татар грамматикасы. Т. III. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – III. т. – 536 б.

Татар телендә тыныш билгеләре: Белешмә / Төз.: Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2004. – 47 б.


*Рус телендә*


Байрамова Л.К., Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 197 с.

Байрамова Л.К. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. – Казань: Изд-во “Дело”, 1997. – 165 с.

Барандеев А.В. Основы научной терминологии: Учеб. пособие. – М.: Мир кн., 1993. – 88 с.

Бахтиярова Н.С. Об изучении стиля научной прозы // Особенности языка научной литературы. – М.: Наука, 1987. – С. 7-37.

Бейсенова Ж.С., Нуркасымова Ж.С. Термин как элемент системы языкового выражения специальных понятий // Бодуэновские чтения: Труды и материалы междунар. науч. конф. (Казань, 11-13 дек. 2001 г.). Т. 2. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. – С. 5-6.

Болдак И.А. О лингвистических особенностях научного текста. – М.: Наука, 1998. – 200 с.

Верещагин Е., Костомаров В. Язык и культура. – М.: Индрик, 2005. – 104 с.

Герд А.С. Основы научно-технической лексикографии. – Л.: ЛГУ, 1986. – 72 с.

Митрохина В.И., Мотовилова О.Г. Типичные словосочетания и выражения. Общенаучная тематика. – М.: Рус. яз., 1982. – 385 с.

Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период (простое предложение). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. – 230 с.

Сафиуллина Ф.С., Байрамова Л.К. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. – Казань: КГУ, 1988. – 196 с.

Сборник правил по татарскому языку для русскоязычных учащихся / Сост.: Нурмухаметова Р.С. – Казань: Гыйлем, 2011. – 72 с.

Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков / Сост.: М.З.Закиев, Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибрагимов, К.З.Зиннатуллина. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. – 230 с.

Закиев М.З. Татарская грамматика. Т. III. Синтаксис. – Казань.: ИЯЛИ АНТ, 1995. – 576 с.

Терминография и перевод научного текста: Межвуз. сб. науч. тр. – Горький: Горьковский гос. ун-т, 1989. – 95 с.

Термины в научной и учебной литературе: Межвуз. сб. – Горький: ГГУ, 1989. – 123 с.

Харисова Ч.М. Татарский язык. Справочник. – Казань: Магариф, 2010. – 200 с.

# СҮЗЛЕКЛӘР

Агишев Х.Г. Русско-татарский словарь словосочетаний: В 2 т. = Русча-татарча сүзтезмәләр сүзлеге: 2 т. / Под ред. М.З.Закиева, С.М.Ибрагимова. – Казань: Матбугат йорты, 1998. – 1 т.: (А-О). – [2-е изд., доп.]. – Казань: Матбугат йорты, 1998. – 512 с.

Агишев Х.Г. Русско-татарский словарь словосочетаний: В 2 т. = Русча-татарча сүзтезмәләр сүзлеге: 2 т. / Под ред. М.З.Закиева, С.М.Ибрагимова. – Казань: Матбугат йорты, 1998. – 2 т.: (П-Я). – Казань: Матбугат йорты, 1998. – 528 с.

Агишев Х.Г., Гайнуллина Л.Х. Русско-татарский словарь словосочетаний для учащихся. Вып. 1. Имена существительные. – Казань, 2001. – 535 с.

Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. М.: Советская Энциклопедия, 1969. – 607 с.

Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – М.: Книга по требованию, 2013. – 608 с.

Ганиев Ф. А., Гаффарова Ф.Ф. Русско-татарский словарь. – Казан: Татар. кн. изд-во, 2001. – 207 с.

Ганиев Ф.А., Гаффарова Ф.Ф. Русско-татарский словарь / Под ред. Ф.А.Ганиева. – Изд. 3-е, испр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. – 240 с.

Гарипов Т.М. Четырехъязычный словарь-минимум: Англо-башкирско-русско-татарский = Дүрт телле сүзлекчә: Инглизчә-башкортча-русча-татарча / Т.М.Гарипов, Ф.А.Басырова; Академия наук Республики Башкортостан; Башк. гос. пед. ин-т; Под ред. Т.М.Гарипова. – Уфа: Башгоспединститут, 1997. – 58 с.

Жеребило Т.В. Словарь лингвистических терминов. – Изд. 5-е, испр. и доп. – Назрань: ООО «Пилигрим», 2010. – 486 с.

Краткий русско-татарский словарь для работников образования: Школа. Дошкольное воспитание / Сост.: К.Р.Галиуллин, Ф.С.Сафиуллина. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. – 127 с.

Розенталь Д.Э., Теленкова М.А. Справочник по русскому языку. Словарь лингвистических терминов. – Минск: Оникс, Мир и Образование, Харвест, 2008. – 623 с.

Русско-татарский словарь / Под ред. Ф.А.Ганиева. – М.: Русский язык, 1984. – 734 с.

Русско-татарский словарь / Ф.А.Ганиев, Ф.Ф.Гаффарова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2001. – 207 с.

Русско-татарский словарь / Под ред. Ф. А. Ганиева. – М.: Русский язык. 1984. – 734 с.

Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча тел белеме терминнары сүзлеге = Татарско-русский терминологический словарь по языкознанию / Фән. мөх. М.З. Зәкиев. – Казан: Хәтер, 1998. – 128 б.

Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча, русча-татарча антонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 2003. – 128 б.

Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.

Сафиуллина Ф.С., Газизова Ф.М. Татарча-русча тезмә сүзләр сүзлеге = Татарско-русский словарь составных слов / Фәнни мөх. М.З. Зәкиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 2002. – 364 б.

Сафиуллина Ф.С., Галиуллин К.Р. Тематический русско-татарский словарь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 287 с.

Сафиуллина Ф.С., Кириллова З.Н., Юсупова А.Ш., Мифтахова И.Г. Татарско-русский словарь однокоренных слов: ок. 4 000 гнезд, 19 000 слов. – Казань: Казанский государственный университет им. В.И.Ульянова-Ленина, 2007. – 468 с.

Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татар теленең омонимнар сүзлеге (русчага тәрҗемә белән). − Казан: Хәтер, 1997. − 96 б.

Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татарча-русча антонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1997. – 97 б.

Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 142 б.

Татарча-русча-инглизчә тел белеме терминнары сүзлекчәсе. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2014. – 160 б.

Татарско-русский словарь = Татарча-русча сүзлек: в 2 т.: ок. 56000 сл., 7400 фразеол. единиц / Акад. наук Респ. Татарстан, Ин-т яз., лит. и искусства им. Г.Ибрагимова; Редкол.: Ш.Н.Асылгараев и др. – Казань: Магариф, 2007. – Т. 1. – 2007. – 725 с.

Татарско-русский словарь = Татарча-русча сүзлек: в 2 т.: ок. 56000 сл., 7400 фразеол. единиц / Акад. наук Респ. Татарстан, Ин-т яз., лит. и искусства им. Г. Ибрагимова; Редкол.: Ш.Н. Асылгараев и др. – Казань: Магариф, 2007. – Т. 2. – 2007. – 727 с.

Татарча-русча уку-укыту сүзлеге: 10000 чамасы сүз = Татарско-русский учебный словарь: Ок. 10000 слов / Ф.Ә.Ганиев, И.А.Абдуллин, Р.Г.Гатауллина, Ф.Ю.Юсупов; Ф.Ә.Ганиев фән. ред. – Казан: Раннур, 2000. – 416 б.

Фатхуллова К.С., Файзрахманова Х.Р. Татарско-русско-английский картинный словарь. – Казань: Магариф, 2009. – 121 с.

## ИНТЕРНЕТ РЕСУРСЛАРЫ


Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. Режим доступа: https://classes.ru/grammar/174.Akhmanova/

Розенталь Д.Э. и др. Словарь лингвистических терминов. Режим доступа: http://www.gumer.info/bibliotek_Buks/Linguist/DicTermin/je.php

Розенталь Д.Э., Теленкова М.А. Словарь-справочник лингвистических терминов – 1985.pdf. Режим доступа: http://filegiver.com/free-download/rozental-d-e-telenkova-m-a-slovar-spravochnik-lingvisticheskikh-terminov-1985.pdf

Словарь лингвистических терминов. Режим доступа: http://enc-dic.com/linguistics/Slovar-lingvisticheski-489/

Словарь лингвистических терминов. Режим доступа: http://www.diclemedicaljournal.com/index.php/list/7-slovar-lingvisticheskih-terminov/,%D0%AF.xhtml

Словарь лингвистических терминов Т.В. Жеребило. Режим доступа: slovari.bibliofond.ru›lingvistics_dictionary_dic/

**Кириллова Зоя Николаевна**

*Печатается по решению Учебно-методической комиссии Ученого совета Института филологии и межкультурной коммуникации КФУ*
*(протокол № 6 от 16 марта 2020 года)*

**Словарь терминов синтаксиса и пунктуации татарского языка**

Учебное пособие для студентов высших учебных заведений

*(на татарском языке)*